مـركـز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام

Language L.60

# Tatari

Version Date: 2025




Part of the

**ISLAMIC e-LIBRARY**

Learn more about Islam with our informative and educational materials, translated to over 50+ languages

@islamicicdxb

CONTENTS


- ИСЛАМГА КЕРЕШ
- МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР — АЛЛАҺНЫҢ АҢА САЛАВАТЫ ҺӘМ СӘЛАМЕ БУЛСЫН
- МӘРЬЯМ УЛЫ ГАЙСӘ: АЛЛАҺНЫҢ РАСУЛЕ.
- ИСЛАМДА ИЛӘҺ ТӨШЕНЧӘСЕ
- КОРЪӘН Кешелеккә соңгы вахи.
- ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ НИНДИ?
- Ислам турында ялгыш карашлар.
- ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ.
- КОРЪӘННЕҢ ФӘННИ МОГҖИЗАЛАРЫ
- ҮЛЕМ ҺӘМ АХИРӘТ.


# ИСЛАМГА КЕРЕШ

TATARI | (01/10) نبذة عن الإسلام | FREE COPY



*Практик һәм урталык булган тормыш юлы.*

*Аллаһ Тәгалә белән ныклы һәм турыдан-туры элемтә.*

*Иләһ төшенчәсенең дөрес һәм аңлаешлы мәгънәсе.*

*һәр заман һәм урын өчен яраклы рисалә.*


جمعية دار البر — Dar Al Ber Society — www.daralber.ae

الإمارات — THE EMIRATES

Your Path To Peace..

مركز المعلومات الإسلامي — Islamic Information Center — للتعريف بالإسلام

تصريح رقم: (2017/139)

دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري — Islamic Affairs & Charitable Activities Department

www.islamicic.com

CONTENTS






# НӘРСӘ УЛ ИСЛАМ?

Ислам – ул бердәнбер хак булган иләһкә ышану (гарәп телендә “Аллаһ”) һәм Аның берүзенә генә гыйбадәт кылу, һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең, Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын, соңгы илче булуына ышану.

Якынча, дүрт кешенең берсе мөселман (23%) – 2 миллиардтан артык мөселман.

Ислам динен тотучы - мөселман дип атала, һәм ул төрле расадан һәм этностан була ала.

# ИМАН һӘМ ЫШАНУ.

Аллаһ Тәгалә безне үзенең аятьләре аша иманга чакыра. Һәм бу белемне безнең җаваплылыгыбызның бер өлеше кылды. Бу тормыш сынавыбызның бер өлеше булып тора. Һәм дөрес юнәлешсез, бернинди мәгълүмат та кешене иманлы итә алмый.

- ✔ Объективлык һәм ачык акыл.
- ✔ Тыйнаклык һәм ихласлык.
- ✔ Безнең барлыгыбызның максаты хакында уйлану.
- ✔ Аллаһның аятьләрен аңларга тырышу.

- ✘ Киртәләр һәм ышанмауга алдан уйланган төшенчәләр.
- ✘ Тәкәбберлек һәм горурлану.
- ✘ Матди әйберләргә генә нигезләнү.
- ✘ Бар нәрсәне дә мәгънәсез дип санау һәм кире кагу.

## БЕРЕНЧЕ СӘБӘП: ГАЛӘМНЕҢ БАШЛАНУЫ.

Аллаһ Тәгаләгә ышану өчен беренче сәбәп галәмнең ничек барлыкка килүе турында уйлау белән бәйле.

Ничек бу галәм барлыкка килде?

- ✘ Ул юклыктан килеп чыктымы? Юклыктан бернәрсә дә килеп чыкмый. Димәк, җавап: юк.
- ✘ Ул үз үзен барлыкка китергәнме? Юк, бу акылга сыймый. Бу ана кешеүз-үзен тудырган сыман кебек булыр.
- ✘ Ул һәрвакыт бар идеме? Юк, фән галәмнең мәңгелек булмаганлыгын һәм аның башлануы барлыгын исбатлый.
- ✔ Аның бар итүчесе яралтучысы бармы? Әйе, мөселманнар аны галәмнән тыш булган нәрсәдер барлыкка китергән дип ышаналар – ул бар итүче Аллаһ.

Ләкин кем Аллаһны бар итте?

Аллаһ бар ителмәде. Ул бу галәмгә һәм мәхлукаткә охшамаган. Аллаһ – ул Беренче, Аңа кадәр бернәрсә дә булмаган, һәм ул Соңгы, Аңардан соң бернәрсә дә юк.

CONTENTS































## ИКЕНЧЕ СӘБӘП: ГАЛӘМНЕҢ КАМИЛ БУЛУЫ.

Аллаһ Тәгаләгә ышану өчен тагын бер гади сәбәп – ул галәмнең ничек камил буларак барлыкка китерелүе турында түбәндәгечә фикерләү:

1.Нәрсәнең дә булса тәртиптә булуы белемгә ишарә итә.

2.Безнең кояш системасы үзенең кануннары белән искиткеч тәртиптә.

3.Галәмебезнең шундый камил халәттә булуы бар кылучының белеменә күрсәтә.

Галәмдә булган күп кенә үзенчәлекләр ачыктан-ачык аның яшәр өчен төзелгәнен күрсәтә. Әгәр дә бу әйберләр әз генә дә үзгәрсә, яшәү мөмкин булмас иде. Моңа мисал буларак:

- Озон катламы.
- Җир шарының кабыгының калынлыгы.
- Кислородның һавадагы күләме.
- Кояшның ераклыгы.
- Кояш, җир һәм айның туры килә торган размерларда булулары.

Әллә шундый зур һәм катлаулы галәм кемнеңдер катнашыннан башка барлыкка килә аламы? Күздә шуны тотарга кирәк Ислам фәнни эзләнүне һәм фикерләүне хуплый. Чөнки фән безгә, Аллаһ Тәгалә үзенең мәхлукларында булдырган, күп кенә могҗизаларны аңлатуда һәм Аның никадәр кодрәтле һәм хикмәтле икәнен аңларга ярдәм итә.

## ӨЧЕНЧЕ СӘБӘП: ВӘХИ – КОРЪӘН.

Коръән Аллаһның барлыгына көчле дәлил булып тора. Һәм аңа үзенең стилендә, хикмәтендә, өндәвендә, матурлыгында һәм укучыга тәэсир итүендә бернәрсә дә охшаш түгел.

- Хаталарсыз, каршылыкларсыз булу.
- Аллаһка дөрес һәм аңлаешлы сыйфатлау бирү.
- Гарәп теленең матурлыгының биеклеге.
- Укый, яза белмәгән Мөхәммәд пәйгамбәргә, Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын, иңүе.
- 1400 елдан артык үзгәрешсез саклануы.
- Кеше характерын тирән рәвештә аңлау.
- Миллионлаган кешеләрнең аны яттан белүләре.
- Элеккеге вакытта кешеләргә әле билгесез булган фәнни ачышлар.

“Шиксез ышанганнар өчен җирдә аятьләр бар. Һәм үзләрегездә дә (ничәмә аятьләр бар). Һаман күрмисезмени?” (Коръән, 51:20-21).

CONTENTS






# КЕМ УЛ АЛЛАҺ ТӘГАЛӘ?

Исламның иң мөһим матурлыкларыннан компромиссыз рәвештә камил бөек бердәнбер булган Аллаһка ышану.

- Аллаһ Тәгалә бер һәм бердәнбер, Аның тиңдәше дә баласы да юк.
- Бар гыйбадәтләргә турыдан-туры Аллаһ Тәгалә генә лаеклы (арадашчысыз).
- Аллаһ Тәгалә камил зат, бер кимчелеге дә, зәгыйфлеге дә юк.
- Аллаһ Тәгалә рәхимлеләрнең Рәхимлесе. Безнең кимчелекле һәм хаталы булуыбызны белә, шулай да, һәрвакыт хаталарыбызны танып, ихластан мәгъфирәт сорау – Аның мәрхәмәтенә ачкыч булып тора.
- Аллаһ Тәгалә бер өлеше белән дә үзенең мәхлукларында түгел һәм башкалар да Аның иләһи сыйфатларында катнашмыйлар.

Исламда Аллаһның кем икәнлеген аңларга тырышканда, аңлашылмаучылыклар һәм буталчыклар сәбәпле Гайсәнең статусы турында да сүз әйтеп үтергә кирәк.

Исламда, Гайсә - пәйгамбәр һәм Аллаһның хөрмәтле илчесе булып тора, ләкин мөселманнар аңа гыйбадәт кылмыйлар, чөнки гыйбадәткә, Гайсәне һәм бар мәхлукатны бар иткән, бердәнбер Аллаһ Тәгалә генә лаеклы. Шуңа күрә, Гайсәне Аллаһ дип, яки Аның улы дип ышану Ислам тәгълиматенә ачык рәвештә каршы килә.

**Әгәр дә Гайсә Аллаһ булса, кемгә ул намаз укыган?**

Насаралар тәгълиматендә, Гайсә, Аллаһ аңардан аерым зат булган рәвештә, сөйләшә һәм үзен тота торган күп кенә мисаллар бар, мисал өчен Гайсә Аллаһка намаз укыган.

**Ничек Аллаһ камил дә, шулвакытта кимчелекле дә була ала?**

Гайсә туган, ашаган, йоклаган һәм белеме чикләнгән булган – болар барысы да Аллаһка лаеклы булмаган сыйфатлар. Аллаһ камил сыйфатлы, ә менә кеше шуның капма-каршысы.

**“Аллаһ улы” дигән төшенчә хакыйкатьтә нәрсәне аңлата?**

“Аллаһ улы” дигән төшенчә, элекке Инҗил телләрендә, Гайсә турында гына түгел, бәлкем, күп кенә кешеләр хакында символик рәвештә “изге кеше” мәгънәсендә кулланылганын күрербез.

**Әгәр дә Аллаһ һәр нәрсәне эшләргә кодрәтле икән, нигә Ул кеше була алмый?**

Аллаһ һәрвакыт камиллек сыйфатларын саклап кала, һәм бу камиллеккә каршы килә торган һичнәрсә дә эшләми. Иләһ төшенчәсе буенча, Ул иләһкә хас булмаган эшләр эшләми. Шулай булгач, әгәр иләһ кешегә әйләнсә, һәм кешеләр сыйфатын алса, моңардан соң ул иләһ булмас.

CONTENTS






**Күп кенә пәйгамбәрләр һәм расүлләр, Адәм, Нух, Ибраһим, Муса, Гайсә, Мөхәммәд һәм башкалар, Аллаһның аларга салаваты һәм сәламе булсын:**

- Бердәнбер илаһ төшенчәсенә әһәмият бирделәр.
- Ялган иләһләрне һәм ышануларны кире кактылар.
- Аллаһка ничек гыйбадәт кылуны аңлаттылар.
- Изгелек һәм күркәм холыкка үрнәк булдылар.
- Итәгатьле булган өчен әҗер (Җәннәт) булачагын аңлаттылар.
- Карышкан өчен җәза (Җәһәннәм) булудан кисәттеләр.

Аллаһ һәрбер өммәткә һәрвакыт бер үк бөек рисалә белән пәйгамбәрләр җибәрде – бердәнбер иләһкә гыйбадәт кылу. Мөселманнар барча пәйгамбәрләрне яратсалар һәм хөрмәт итсәләр дә, аларга гыйбадәт кылмыйлар һәм аларны иләһкә әйләндермиләр, чөнки гыйбадәт бердәнбер Аллаһның хакы.

## ТОРМЫШ МАКСАТЫ

Хикмәтле Аллаһ безне максатсыз яшәргә, фәкать үзебезнең теләкләребезне һәм инстинктларыбызны туйдырырга барлыкка китермәде. Бәлкем безнең бөек максатыбыз бар – Аллаһка ышану һәм Аның берүзенә генә гыйбадәт кылып, Аның шәригате буенча яшәү. Бу туры юл – бөтен яктан да бәхетле һәм уңышлы тормышның сәбәбе булып тора.

Аллаһның чиксез хикмәтеннән – Ул безне бар итте һәм Үзен тану, тормыш тәҗрибәсен яшәү һәм үз теләгебез белән сайлау мөмкинчелеге бүләк итте.

Ислам – камил тормыш рәвеше. Ул мөселманнарны җәмгыятьтә тыныч, әхлаклы, файдалы булырга өйрәтә. Исламда гыйбадәт – ул намаз уку һәм дога кылу гына түгел, бәлкем, ул Аллаһ риза булган барлык гамәлләрне үз эченә алган киң мәгънә. Түбәндә кайбер мисаллар:

- Хәләл мал кәсеп итү.
- Гаделсезлеккә каршы тору.
- Ятимнәрне кайгырту.
- Тирә-юнне кайгырту.
- Сабырлык һәм тыйнаклык.
- Җәмгыятькә файда китерү.
- Ата-анага хөрмәт.
- Гаделлек ягында булу.
- Күршеләргә яхшылык күрсәтү.
- Аллаһка тәкъвалы булу.
- Гаиләне тәэмин итү.
- Тугрылык.

Гыйбадәт эшләрендә Аллаһны ризалаштыру тугры нияте булырга тиеш, һәм аларны Ислам кушканча, дөрес итеп башкару тиешле.

CONTENTS






# ИСЛАМ НӘРСӘ ӘЙТӘ...

Хатын-кыз: Хатын-кыз Исламда ихтирамның иң биек дәрәҗәләренә ия. Аңа мәхәббәт, хөрмәт һәм ихтирам күрсәтү тиешле. Алар ир-атларның иптәшләре, һәм аларга карата гаделсезлекне берничек тә аклап булмый.

Терроризм: Ислам, нинди дин вәкилләре булуына карамастан, гаепсез кешеләрне җәберләүне тыя һәм җинаятькә саный. Сугыш Исламда җәмгыятьне саклау һәм гаделсезлекнең таралуыннан тыю кебек бөек һәм законлы максатлар өчен генә рөхсәт ителә.

Хәләл ризык: Мөселманнарга ашарга рөхсәт ителгән ризык – хәләл ризык була. Хайван һәм кош-корт кешечә, рәнҗетмичә, Аллаһ исемен әйтеп (бисмилләһ дип), чалынырга тиеш.

Эволюция: Аллаһ Тәгалә маймыллардан әкренләп эволюция рәвешендә түгел, ә беренче кеше булара Адәмне соңгы формасында бар итте. Һәм моны турыдан-туры фән аша исбатлап та, кире кагып та булмый, чөнки бу уникаль һәм гаҗәеп тарихи вакыйга – могҗиза булды. Шуңа күрә, ул фәнни тәҗрибә эзләнү өлкәсенә керә алмый.




HOTLINE
+971 56 204 2045
islamicicdxb
islamicic.com
info@islamicic.com
+971 4 355 5223
DOWNLOAD TATARI FLYER
www.iicdxb.com/tatari

CONTENTS


ИСЛАМГА КЕРЕШ

МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР

МӘРЬЯМ УЛЫ ГАЙСӘ: АЛЛАҺНЫҢ РАСУЛЕ.

ИСЛАМДА ИЛӘҺ ТӨШЕНЧӘСЕ

КОРЪӘН Кешелеккә соңгы вәхи.

ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ НИНДИ?

Ислам турында ялгыш карашлар.

ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ.

КОРЪӘННЕҢ ФӘННИ МОГҖИЗАЛАРЫ

ҮЛЕМ һӘМ АХИРӘТ.


# МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР

## АЛЛАҺНЫҢ АҢА САЛАВАТЫ һӘМ СӘЛАМЕ БУЛСЫН

TATARI | (02/10) | النبي محمد عليه الصلاة والسلام | FREE COPY





جمعية دار البر
Dar Al Ber Society
www.daralber.ae

الإمارات
THE EMIRATES

Your Path To Peace..

مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام

تصريح رقم:
(2017/139)

دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري
Islamic Affairs & Charitable Activities Department

www.islamicic.com

CONTENTS































# МӨХӘММӘД кем ул? (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын)

Мөселманнар Мөхәммәд (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) кешеләрне Аллаһка гына буйсынырга һәм Аңа гына табынырга чакыру өчен җибәрелгән озын пәйгамбәрләр чылбырында соңгы Пәйгамбәр дип ышаналар. Бу пәйгамбәрләрнең кайберләренә Адәм, Нух, Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Ягъкуб, Йосыф, Муса, Давыт, Сөләйман һәм Гайсә керәләр (Аллаһның аларга салаваты һәм сәламе булсын).

*"Сезнең өчен, Аллаһтан һәм ахирәт көненнән курка торган кешеләр өчен һәм Аллаһны күп искә төшерә торган кешеләр өчен, Аллаһның Пәйгамбәрендә күркәм, хуш булган мисал бар иде."*

Коръән, 33:21

Мөселманнар Муса (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) Тәүрат (Мусага үзгәртелмәгән хәлендә җибәрелгән вәхи(китап)) белән җибәрелгән һәм Гайсә (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) Инҗил (үзгәртелмәгән хәлендә җибәрелгән вәхи(китап) - хәзерге версияләре түгел) белән җибәрелгән дип ышаналар. Шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәр дә (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) кешеләргә Коръән белән, аның тәгълиматларын ничек кулланырга икәнен күрсәтү өчен җибәрелгәненә ышаналар.

Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) хатыны Гайшәдән бервакыт Пәйгамбәрне (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) сыйфатлавы соралгач, ул “аның холкы Коръән иде" дип җавап бирде, ягъни ул Коръәннең күркәм тәгълиматларын җентекләп көндәлек тормышында ашырды. Без аның бу күркәм тәгълиматларны хәерле эшләргә ничек тәрҗемә иткәнен күрсәтербез.

## Шәфкать-мәрхәмәт илчесе.

*"һәм без (Аллаh) сине (Мөхәммәдне) галәмнәргә шәфкать-мәрхәмәт булырак кына җибәрдек."*

Коръән, 21:107

Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) кешеләрне намаз укырга, ураза тотарга һәм сәдака бирергә чакырган кебек, кешенең Аллаһка ышануы башкалар белән мөгамәләсенә дә тәэсир итәргә тиешлеген өйрәтте. Ул әйтте: "Сезнең иң хәерлегез – әдәп-әхлагы белән иң күркәм булганыгыз".

Пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) күп кенә сүзләре ышану белән гамәл арасындагы бәйләнешкә басым ясый, мәсәлән: "Кем Аллаһка һәм Ахирәт көненә ышана икән, күршесенә зыян китермәсен, һәм кем Аллаһка һәм Ахирәт көненә ышана икән, кунагына юмартлык күрсәтсен, һәм кем Аллаһка һәм Ахирәт көненә ышана икән, хәерле сүзләр сөйләсен яки дәшмәсен. " (Бохари, 6018).

CONTENTS































Илчеләрнең соңгысы (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) кешеләр бер-берсенә рәхимлелек күрсәтергә һәм хөрмәт итәргә өйрәтте һәм әйтте: "Башкаларга рәхимлелек күрсәтмәгән кешегә рәхимлелек күрсәтелмәячәк." (Бохари, 5997).

Башка риваятьтә кайбер кешеләр Пәйгамбәрдән (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) Аллаh Тәгалә кяферләрне җәзаласын дип дога кылуын сорадылар, ләкин ул болай дип җавап бирде: "Мин ләгънәт өчен түгел, мәрхәмәт буларак җибәрелдем." (Мөслим, 2599).

## Гафу итү.

*"Алар гафу итсеннәр һәм игътибар итмәсеннәр. Әллә Аллаhның сезне гафу итүен теләмисезме? "*

Коръән, 24:22

Пәйгамбәребез (Аллаhның аңа салаваты һәм сәламе булсын) кешеләр арасыннан иң гафу итүче һәм игелекле кеше иде. Әгәр дә кемдер аны рәнҗетсә, ул аны кичерер иде, һәм кеше кырысрак булса, ул сабырлырак булыр иде. Ул бик йомшак һәм кичерүче иде, аеруча өстенлек һәм үч алу көче аның ягында булганда.

Мөхәммәд (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) гафу итүче һәм кичерүче иде, һәм аңа карата булган берниндиженаять яки агрессия аның гафу итүеннән өстенрәк чыкмады. Ул Коръәннең киләсе аятен үтәп, гафу итүнең һәм игелекнең иң яхшы үрнәге иде:

"(Әй, Мөхәммәд) гафу ит, игелекне әмер ит, һәм наданнардан йөзеңне чөер." (Коръән, 7:199).

## Тигезлек.

*“Аллаh каршында сезнең иң хөрмәтлегез – Аллаhка тәкъвалы булганнарыгыз.”*

Коръән, 49:13

Түбәндәге хәдисләрендә Пәйгамбәребез (Аллаhның аңа салаваты һәм сәламе булсын) Аллаh Тәгалә каршында барлык кешеләр дә бертигез булуын өйрәтте:

“(Бар кешелекнең башлангычы булган) сезнең атагыз - Адәм, ә Адәм балчыктан. Гарәпнең гарәп булмаганнан, һәм акның карадан өстенлеге юктыр, илләдә мәгәр тәкъвалык белән .” (Әхмәд, 23489).

“Аллаh Тәгалә сезнең тышкы кыяфәтегез һәм мал-байлыгыгызга карамый, ләкин ул сезнең йөрәкләрегезгә һәм гамәл-эшләрегезгә карый.” (Мөслим, 2564).

Пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) бер сахабәсе икенчесенә кимсетеп, "кара хатын улы!"- дип дәшкән, шулчак Пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) моңа ачуы чыккан һәм әйткән: “Син аны әнисенең кара булуы белән гаепләдеңме? Синдә (әле һаман исламга кадәр булган) җаһилият эзләре бар.” (Бохари, 30).


CONTENTS



























## Миһербанлылык.

*“Яхшылык белән начарлык бертигез булмас. Син инде начарлыкны иң яхшы булган яхшылык белән кайтар. Шулчакта синең белән дошман булган кеше синең якын дустың булып калыр.”*

Коръән, 41:34

Аллаһның соңгы пәйгамбәрен (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) сыйфатлаганда, "ул явызлык кылучыларга начарлык белән кайтармый, ләкин гафу итә һәм кичерә иде" (Бохари, 4838) дип әйтелә. Һәм шәхси һөҗүмнәргә һәм җәбер-золымнарга аның мөгамәләсе менә шундый иде.

Ислам чыганакларында Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) аны рәнҗеткәннәрдән үч алырга мөмкинлеге була торып та, ләкин ул гафу итүенең күп очраклары бар.

Ул кешеләргә авырлыклар һәм сынаулар вакытында сабырлык күрсәтергә өйрәтә иде. Ул (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) сахабәләренең берсенә болай диде: "Үз көче белән кешеләрне җиңүче көчле түгел, ә көчле ул шул - ачуы чыкканда үз-үзен кулда тота белүче." (Бохари, 6114).

Сабыр һәм миһербанлы булу, мөселманга һөҗүм иткәндә, үз-үзен якламаска тиеш дигән сүз түгел. Мөхәммәд пәйгамбәр (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) болай диде: "Дошман белән очрашырга теләмәгез һәм Аллаһтан иминлек сорагыз, ләкин очрашсагыз, сабыр булыгыз (дошманга каршы нык торыгыз)." (Бохари, 2966).

## Йомшаклык.

*“Аллаһның рәхмәте белән, син аларга йомшак булдың, явыз холыклы, каты күңелле булсаң, синең тирәңнән алар таралырлар иде.”*

Коръән, 3:159

Пәйгамбәребезгә (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) ун ел хезмәт иткән сахабәсе, пәйгамбәребез аның белән мөгамәләдә һәрвакыт йомшак булуын әйтте. “Мин берәр нәрсә эшләгәндә, миңа: ник болай эшләдең дип әйтмәде, һәм мин берәр нәрсә эшләмәгәндә, миңа: ник болай эшләмәдең дип әйтмәде.” (Әхмәд, 12784). Һәм ул кешеләрнең иң сөйкемлесе иде.

Бервакыт Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) хатыны каршысында бер кеше пәйгамбәребезне мыскыл иткәч, аның ачуы чыккан, шунда пәйгамбәребез (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) аңа киңәш бирде: "Әй, Гайшә, йомшак һәм тыныч бул, Аллаһ йомшактыр, һәм һәр эштә йомшаклыкны ярата." (Бохари, 6024).

Ул (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) шулай ук: “Әгәр дә берәр нәрсәдә йомшаклык табылса, ул аны бизи, һәм берәр нәрсәдән алынса, ул аны ямьсез итә.” (Мөслим, 2594).

CONTENTS




## Тыйнаклык.

*“Аллаһның киң рәхмәтле коллары шундый кешеләр, алар, җир өстендә йөргәндә, салмак кына йөрерләр. һәм надан кешеләр аларга дәшкән чакта, “Сәлам сезгә!” – диярләр.”*

Корьән, 25:63

Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) кешеләрне аңа хөрмәт йөзеннән торып басуны тыя иде. Ул кайда буш урын булса, шунда утыра һәм беркайчан да күренекле яки биек урын эзләми иде. Ул беркайчан да үзенең сахабәләреннән аерылып торган кием кимәгән. Ул ярлылар һәм мохтаҗлар белән аралаша, картлар белән утыра, һәм тол хатыннарга булыша иде. Аны белмәгәннәр, кешеләр арасыннан аны аера алмыйлар иде.

Сахабәләренә мөрәҗәгать итеп, ул болай диде: “Аллаһ миңа: сезгә тыйнак булырга кирәклеген вәхи иңдерде. Беркем дә башкалардан өстенлек күрсәтеп горурланырга, һәм башкаларны җәберләргә тиеш түгел.” (Мөслим, 2865).

Аның тыйнаклыгына мисаллардан: Аллаһтан башка аңа гыйбадәт кылырлар дип куркуы, шуңа да ул (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) болай диде: “Насаралар Мәрьям Улы Гайсәне (чиктән ашып) мактаган кебек, мине (чиктән ашып) мактамагыз. Мин (Аллаһның) бәндәсе генә; шуңа да миңа: Аллаһның бәндәсе һәм Аның Рәсүле дип әйтегез.” (Бохари, 3445).

## Үрнәк ир.

*“Алар белән (тормыш иптәшләрегез) яхшы мөнәсәбәттә булыгыз.”*

Корьән, 4:19

Пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) яраткан хатыны Гайшә болай диде: "Ул өй эшендә булыша иде, кайчак киемен тегер, аяк киемен төзәтер һәм сезнең кебек үк өй эшләрен башкарыр иде.” (Әхмәд, 25341).

Ул (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) үзе генә үрнәк ир булып калмады, бәлкем сахабәләрен дә аның үрнәгенә ияреpгә өндәде: “Иман китерүчеләрнең иң камилләре – әдәп-әхлагы белән иң күркәм, һәм хатыннарына иң йомшак булганнары.” (Әхмәд, 24204).

## Яхшы үрнәк.

Моңарчы язып үтелгәннәр Мөхәммәд пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) тормышын күзаллау гына иде.

Дәвамлы рәвештә, Ислам динен начар яктан күрсәтергә тырышкан массакүләм мәгълүмат чаралары нигезендә


CONTENTS

























*“Син бит (әй Мөхәммәд), шиксез, киң холыклысың.”*
Коръән, 68:4

Мөхәммәд пәйгамбәрне (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) күзаллаган кайбер кешеләр өчен искә алынган игелек һәм шәфкатьлелек үрнәкләре кәтелмәгән хәл булырга мөмкин.

Исламны аңларга тырышканда, аның чыганакларына турыдан-туры мөрәҗәгать итү мөһим: Коръән һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) сүзләре һәм эшләре. Һәм Ислам турында кайбер мөселманнарның хаталы эшләре нигезендә хөкем итү һичшиксез гаделсез булыр.

## Мөселман булмаган кешеләрнең аның хакында әйтелгән сүзләре.

Һиндстан бәйсезлеге хәрәкәтенең төп сәяси һәм рухи лидеры Махатма Ганди болай диде:

*“Кылыч түгел, ә Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) гадилеге, вәгъдәләренә игътибарлы һәм тугъры булуы, иптәшләренә һәм иярченнәренә эчкерсезлеге һәм тирән тугърылыгы, кыюлыгы белән бергә Раббысына һәм үзенә йөкләнгән бурычына тулысынча ышануы кебек сыйфатлар юл ачтылар һәм авырлыкларны үтәргә ярдәм иттеләр.”*

Британия драматургы Джордж Бернард Шоу болай дип игълан итте:

*“ Проблемаларны чишү өчен, дөнья бүгенге көндә Мөхәммәд кебек кешегә бик мохтаҗ. Урта гасырдагы дини кешеләр, үзләренең наданлыгы һәм тискәре карашлары аркасында, аны бик караңгы итеп сурәтләгәннәр, һәм христиан диненең дошманы дип санаганнар. Ләкин бу кешенең хәленә күз салгач, мин аның гаҗәеп һәм могҗизалы булуын һәм христиан диненә дошман түгеллеген таптым, бәлкем аның кешелек коткаручысы дип аталырга тиеш дигән нәтиҗәгә килдем. Минем уйлавымча, аңа бүген дөнья белән идарә итәргә мөмкинчелек бирелсә, ул безнең проблемаларны чишәр иде һәм дөнья көткән тынычлыкны һәм бәхетне тәэмин итәр иде.”*

CONTENTS


ИСЛАМГА КЕРЕШ

МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР (АЛЛАҺНЫҢ АҢА САЛАВАТЫ һӘМ СӘЛАМЕ БУЛСЫН)

МӘРЬЯМ УЛЫ ГАЙСӘ: АЛЛАҺНЫҢ РАСҮЛЕ.

ИСЛАМДА ИЛӘҺ ТӨШЕНЧӘСЕ

КОРЪӘН Кешелеккә соңгы вәхи.

ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ НИНДИ?

Ислам турында ялгыш карашлар.

ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ.

КОРЪӘННЕҢ ФӘННИ МОГҖИЗАЛАРЫ

ҮЛЕМ һӘМ АХИРӘТ.


# МӘРЬЯМ УЛЫ ГАЙСӘ: АЛЛАҺНЫҢ РАСҮЛЕ.

TATARI (03/10) النبي عيسى عليه الصلاة والسلام FREE COPY

## *Мөселманнар Гайсәне*

*(Аллаһның аңа сәламе булсын) яраталар.*

Dar Al Ber Society
www.daralber.ae

الإمارات THE EMIRATES

*Your Path To Peace..*

مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام


تصريح رقم:
(2017/139)

دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري
Islamic Affairs & Charitable Activities Department


www.islamicic.com

CONTENTS































Гайсә (Аллаһның аңа сәламе булсын) - бөтен дөнья буенча миллиардлаган кеше яраткан һәм хөрмәт иткән шәхес, ләкин бу зур шәхес тирәсендә күп буталчыклар бар. Барысы да, мөселманнар да, насаралар да Гайсәне (Аллаһның аңа сәламе булсын) хөрмәт итәләр, ләкин аңа төрлечә карыйлар.

Бу брошюра Гайсә (Аллаһның аңа сәламе булсын) тирәсендәге сорауларны ачыклауны максат итеп куя: Гайсә (Аллаһның аңа сәламе булсын) иләһ булганмы, әллә ул Аллаһ тарафыннан җибәрелгәнме? Чын Гайсә (Аллаһның аңа сәламе булсын) кем булган?

## Гайсә иләһ буларак.

Насараларның күбесе "Гайсә - иләһ" яки Троицаның бер өлеше - ул җирдә Аллаһның гәүдәләнеше, һәм Аллаһ кеше формасын алган дип әйтәләр. Ләкин, изге язмалар буенча, Гайсә туган, ашаган, йоклаган, дога кылган һәм белемнәре чикләнгән, һәм бу барлык сыйфатлар Аллаһка туры килми. Аллаһ камиллек сыйфатларына ия, ә кешедә киресенчә, андый камиллек юк. Шулай булгач, ничек берьюлы ике капма-каршылык бер затта җыелырга мөмкин?

Ислам Аллаһның һәрвакыт камил булуын өйрәтә. Иләһнең кеше булуына ышану - Аллаһның камил булмавы (яки ниндидер вакытта) камил булмаганлыгын дәгва кылу булачак (Аллаһ моның барысыннан да пакъ). Насара үзеннән сорарга тиеш, кайчандыр зәгыйфь ярдәмсез бала булган, ашау-эчү яки йокысыз яши алмаган зат Иске Гаһедтә сурәтләнгән чиксез кодрәтле Аллаһ була аламы? Һичшиксез юк.

Берәү сорарага мөмкин: "Әгәр Аллаһ һәрнәрсәне эшли алса, ни өчен ул кеше була алмый?"

Төшенчә буенча, иләһ аңа туры килми торган эшләрне эшләми, шуңа күрә иләһ кеше булып, кеше сыйфатларын үз өстенә алса, ул, әлбәттә, иләһ булмас иде.

Изге Китапның кайбер аңлашылмаган шигырьләре Гайсәнең ниндидер дәрәҗәдә иләһ булуын күрсәтү өчен ялгыш кулланылырга мөмкин. Ләкин без Изге Китапның шигырьләрен карасак, ап-ачык турыдан-туры кат-кат Гайсәнең Аллаһның расүле булган кеше булуыннан артык бернәрсә дә күрмибез. Изге китапта Гайсә, Аллаһның бәндәсе һәм Аллаһтан аерым зат булган рәвештә, сөйләшүен һәм үзен тотуын күрербез. Мәсәлән:

- Гайсә “йөзтүбән капланып дога кылды”. (Маттай, 26:39). Әгәр Гайсә иләһ булса, иләһ йөзтүбән капланып дога кылыр идеме? Һәм ул кемгә дога кылыр иде?
- Изге китап Гайсәне пәйгамбәр дип атый. “Гайсә Иерусалимга килеп кергәч,бөтен шәһәр кузгалды.
- Кем бу? - дип сораштылар кешеләр.

CONTENTS






- Бу - Гайсә, Галиләядәге Насарадан пәйгамбәр, - дип җавап бирде халык” (Маттай, 21:10-11). Шулай итеп Гайсә ничек иләһ тә һәм шул ук вакытта Аллаһ пәйгамбәре дә була ала?
- Гайсә (Аллаһның аңа сәламе булсын) әйтте: “Мине яратсагыз, Атам янына баруыма куаныр идегез, чөнки Атам миннән бөегрәк”. (Яхъя, 14:28).
- Гайсә (Аллаһның аңа сәламе булсын) әйтте: “Мин үземнең Атам һәм сезнең Атагыз янына, һәм үземнең Аллам һәм сезнең Аллагыз янына күтәреләм.” [Яхъя 20:17] Әгәр Гайсә иләһ булса, нигә ул: “үземнең Аллам һәм сезнең Аллагыз” дип әйтә, һәм ул кем янына күтәрелә?

Әгәр Гайсә иләһ булса, ул кешеләргә аңа табынырга ап-ачык итеп әйтер иде, һәм Изге Китапта моны күрсәтүче ачык шигырьләр булыр иде. Ләкин ул киресенчә эшләде һәм аңа табынучыларны хупламады: “Миңа табынулары бушка”. (Маттай, 15:9).

## “Аллаһ Улы”.

Насараларның күбесе "Гайсә - Аллаһ Улы" дип әйтәләр, ләкин без үз-үзебездән сорарга тиеш, бу нәрсәне аңлата?

Әлбәттә, Аллаһ физик улы булудан ерак. Кешеләрнең кеше балалары бар, һәм бу башка җан ияләрендә дә шулай ук. Ләкин Аллаһның баласы булу нәрсә аңлата соң?

> **“Аллаһ өчен бала тоту һич тә була торган эш түгел. Ул Аллаһны андый эшләрдән пакьләгез. Әгәр Аллаһ бер эшне булдырырга теләсә, Ул аңа тик: “Бул!” – дип әйтә дә, ул шунда ук була.”**
> **Коръән, 19:35**

Туры мәгънәдә кабул итү урынына, без "Аллаһ Улы" төшенчәсенең символик рәвештә иң элек Изге Китап телләрендә "изге кешеләр" хакында кулланылганын табабыз. Бу Гайсә өчен генә түгел, шулай ук Давыт, Сөләйман һәм Ягъкуб өчен куллануын күрәбез: “...Исраиль - Минем беренче углым”. (Чыгыш, 4: 22). Чынлыкта, изге кеше Алланың "улы" дип атала: "Аллаһы Рухы йөрткән кешеләрнең һәммәсе дә - Аллаһы балалары." (Римлыларга хат, 8:14).

## “Ата һәм иләһ”.

Шулай ук, "Ата" сүзе Аллаһка карата кулланылганда, ул туры мәгънәдә кабул ителергә тиеш түгел. Киресенчә, бу - Аллаһ барлыкка китерүче, саклаучы һәм ризыкландыручы дип әйтү ысулы. "Ата" сүзенең бу символик мәгънәсен аңлар өчен бик күп шигырьләр бар, мәсәлән: “Аллаһы – бер, Ул – барысының да Атасы”. (Эфеслеләргә хат, 4:6).

Шулай ук, Гайсәне шәкертләре кайвакыт “Хуҗа” дип атыйлар иде. Бу термин Инҗилнең асыл телләрендә, Аллаһ өчен дә, дәрәҗәле кешеләр өчен дә кулланыла иде. Мәсәлән, юнан(грек) телендәге


CONTENTS



























Яңа Гаһедтә “кириоз” атамасы “Хуҗа(Раббы)” өчен дә, йөзем бакчасының хуҗасы өчен дә (Маттай, 20:8) һәм тыңламаучан хезмәтчене кыйнаган хуҗаны атау өчен дә кулланыла (Лук, 20:42-47).

Инҗилнең башка өлешләрендә Гайсә хәтта шәкертләре тарафыннан “Аллаһның хезмәтчесе” дип атала: «безнең аталарыбызның Алласы, үзенең хезмәтчесе Гайсәне шөһрәтле итте”. (Рәсүлләр, 3:13). Бу, “Хуҗа” сүзе Гайсәгә (Аллаһның аңа сәламе булсын) карата кулланылганда, иләһилек түгел, ә хөрмәт исеме икәнлеген ачык итеп күрсәтә.

## Гайсә: Пәйгамбәр.

Яһүдләр Гайсәнең (Аллаһның аңа сәламе булсын) көтелгән Мәсих булуын кире кагалар. Бу, аңа илә яки Аллаһ улы дип табына торган Насаралар диненә бик каты каршы килә. Ә Ислам урталыкта тора һәм Гайсәне Аллаһның хөрмәтле пәйгамбәре, рәсүле, һәм көтелгән Мәсих дип таный, ләкин мөселманнар аңа табынмыйлар - чөнки гыйбадәт Гайсәне һәм барча мәхлукатне барлыкка китергән бердәнбер Аллаһка гына кылына.

**“(Гайсә) әйтте: “Дөреслектә, мин Аллаһның колы(бәндәсе). Ул миңа изге китап бирде һәм мине пәйгамбәр кылды.”**
**Коръән, 19:30**

## Могҗизалы туу.

Коръәнгә нигезләнеп, Аллаһ Тәгалә Җәбраил фәрештәне гыйффәтле кыз Мәрьямгә, кеше сурәтендә җибәрә, һәм ул аңа могҗизалы рәвештә атисез баласы туу хакында хәбәр итә.

**“Ул (Җәбраил фәрештә): “Мин, сиңа саф бер ир бала бүләк итү өчен, синең Раббың Аллаһ тарафыннан җибәрелдем”, – диде. Мәрьям: “Ничек минем ир балам була алсын?! Миңа бит бер кеше дә кагылмады, һәм мин (беркайчан да) зина кылучы фахишә булмадым”, – диде. Ул әйтте: “Шулай булачак ул. Синең Раббың Аллаһ әйтте: “ Ул (атасыз бала тудыру) –Минем өчен җиңел эш. Без аны кешеләргә бер аять һәм Үзебездән бер рәхмәт иттек. Бу инде - карар кылынган бер эш”, – диде.”**
**Коръән, 19:19-21**

Кайберәүләр Гайсәнең могҗизалы тууы аның илә булуына дәлил дип әйтәләр. Ләкин, Гайсә атисез барлыкка килгән беренче кеше түгел, чөнки аңа кадәр булган Адәм пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе булсын) атисе дә, әнисе дә булмаган. Аллаһ Тәгалә әйтә:

**“Аллаһ каршында Гайсәнең мисалы Адәмнеке кебек охшаш. Ул аны (Адәмне) балчыктан яралтты, аннары аңа: “Бул”,-дип әйтте һәм ул булды. (Бу) Хак – Раббыңнан, Шулай булгач, шикләнүчеләрдән булма.”**
**Коръән, 3:59-60**

Әгәр дә Гайсәгә атисез туганга күрә табыналар икән, һичшиксез, Адәм табынуга лаеклырак булыр иде, чөнки ул ата-анасыз барлыкка килде.

CONTENTS































# Гайсәнең могҗизалары.

Гайсә могҗизалы рәвештә атисез туган һәм шулай ук Аллаһның ихтиряры белән зур могҗизалар күрсәткән.

Ул әнисен фәхешлектә гаепләгән кешеләрдән яклау өчен, бишектә сабый хәлендә сөйләште. Корьән шулай ук, Гайсәнең Аллаһның ихтыяры белән үлгәннәрне терелтүен, махау авыруларын һәм сукырларны шифаландыруын искә ала.

Гайсәнең (Аллаһның аңа сәламе булсын) могҗизалар күрсәтүе аның Аллаһка итәгатьле, тугъры бәндәсе һәм рәсүле булуын аңлата. Чынлыкта, күп Рәсүлләр могҗизалар күрсәттеләр, алар арасында Нух, Муса һәм Мөхәммәд (Аллаһның аларга салаваты һәм сәламе булсын) һәм бу могҗизалар Рәсүлләрнең дөреслеген күрсәтү өчен, Аллаһның әмере һәм ихтияры белән генә булды.

# Гайсәнең миссиясе.

Иске Гаһеднең Ибраһим, Нух һәм Юныс кебек пәйгамбәрләре беркайчан да Аллаһ Троицаның бер өлеше дип игълан итмәделәр, һәм Гайсәгә аларның коткаручысы дип ышанмадылар.

Аларның чакыруы гади иде: бердәнбер Аллаһ бар һәм Ул гына синең гыйбадәтеңә лаеклы. Аллаһ меңләгән еллар дәвамында шул мөһим максат белән пәйгамбәрләр җибәрде, аннары кинәт үзгәртеп, хәзер Ул - Троицаның бер өлеше дип әйтү һәм котылу өчен Гайсәнең Аның улы һәм иләһ булуына ышану акылга һәм мантыйкка туры килми торган әйбер.

Хакыйкать шунда, Гайсә Иске Гаһедтәге барлык пәйгамбәрләр чакырган бер үк максатка чакырды. Инҗилдә бу төп максатны ассызыклаган өзек бар. Бер кеше Гайсә янына килеп: "Әмерләрнең кайсысы мөһимрәк?" - дип сорады. Иң мөһим әмер шушыдыр, - дип җавап бирде Гайсә: " Тыңла, Исраил халкы! Раббы Аллабыз – бердәнбер Раббы". (Марк, 12:28-29). Шулай итеп, Гайсәнең тәгълиматы буенча иң мөһим әмер һәм иң төп ышану - иләһнең бердәнбер булуы. Әгәр дә Гайсә иләһ булса, ул: "Мин - Аллаһ, миңа табыныгыз", - дип әйтер иде. Ләкин ул киресенчә, Аллаһның бирлеген раслаган Иске Гаһеднең шигырьләрен кабатлады.

Бу Гайсәнең миссиясенә дә, Ислам тәгълиматына да туры килә, анда Гайсә Исраил

> **"Гайсә ачык дәлил белән килгәч: "Мин сезгә хикмәт китердем һәм сез төрле фикердә була торган нәрсәләрне сезгә аңлатып бирү өчен килдем. Шулай булгач, сез Аллаһтан куркыгыз һәм миңа буйсыныгыз. Дөреслектә, Аллаһ – минем дә Раббым, сезнең дә Раббыгыз. Сез Аңа гына гыйбадәт кылыгыз. Менә бу – туры юл", – диде."**
>
> Корьән, 43:63-64


CONTENTS



























балаларына, үткән пәйгамбәрләрнең бөтен кешелеккә булган чакыруын – гыйбадәткә бердәнбер Хак Аллаһ лаеклы дигән ышануны раслау өчен җибәрелгән.

Гайсә расүл һәм Аллаһның хөрмәтле бәндәсе буларак, Аллаһның әмерләренә түбәнчелек белән буйсынды. Шулай итеп, ул һәрбер мөселман кебек - Аллаһның ихтыярына һәм әмерләренә буйсына иде.

## Гайсә Ислам динендә.

Гайсә Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырган хөрмәтле пәйгамбәр иде.

Бу Изге Китапта ап-ачык һәм шулай ук Коръән белән дә расланган. Ислам ышануы чын Гайсәнең кем булуын аңлата, һәм шул ук вакытта Аллаһның бөеклеге, бердәнберлеге һәм камиллеге турында саф ышануны саклый.

Без сине алга таба карарга һәм Исламны өйрәнергә чакырабыз. Бу башка дин түгел, бу Нух, Ибраһим, Муса, Гайсә һәм Мөхәммәд (Аллаһның аларга салаваты һәм сәламе булсын) чакырган бер үк рисалә, вәхи. Ислам – “Аллаһка буйсыну” дигәнне аңлата һәм ул камил яшәү рәвеше булып тора, бу - кешенең Аллаһ белән мөнәсәбәтләрендә һәм Аның мәхлукатлары белән мөгамәләсендә изгелек күрсәтергә чакыра. Ислам, Аллаһның - Гадел һәм Рәхимле булуын, гөнаһларны кичерү өчен үзен корбан итәргә тиеш түгеллеген, һәм беркем дә гөнаһта тумаганлыгын өйрәтә. Аллаһ һәркемне эшенә карап хөкем итә һәм һәркем үз эше өчен җавап бирә.

Ислам безне Аллаһның барлык пәйгамбәрләрен яратырга һәм хөрмәт итәргә өйрәтә, ләкин аларны ярату һәм хөрмәт итү аларга табыну дигән сүз түгел, чөнки гыйбадәткә Аллаһ кына лаеклы. Гайсәне Аллаһның пәйгамбәре дип тану, Исламны кабул итү - синең Гайсә белән бәйләнешеңне үзгәртү яки югалту дигән сүз түгел. Бу аның асыл һәм саф тәгълиматларына кире кайтуны аңлата.

CONTENTS


ИСЛАМГА КЕРЕШ
МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР
МӘРЬЯМ УЛЫ ГАЙСӘ: АЛЛАҺНЫҢ РАСУЛЕ.
ИСЛАМДА ИЛӘҺ ТӨШЕНЧӘСЕ
КОРЪӘН Кешелеккә соңгы вәхи.
ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ НИНДИ?
Ислам турында ялгыш карашлар.
ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ.
КОРЪӘННЕҢ ФӘННИ МОГҖИЗАЛАРЫ
ҮЛЕМ ҺӘМ АХИРӘТ.


# ИСЛАМДА ИЛӘҺ ТӨШЕНЧӘСЕ

TATARI | (04/10) مفهوم الإله في الإسلام | FREE COPY

*Юктан бар итүчедән бөегрәк беркем дә юк.*


جمعية دار البر
Dar Al Ber Society
www.daralber.ae

الإمارات
THE EMIRATES

Your Path To Peace..

مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام

تصريح رقم:
(2017/139)
دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري
Islamic Affairs & Charitable Activities Department

www.islamicic.com

CONTENTS






# Аллаһ бармы?

Аллаһның барлыгына ышануның бик күп рациональ сәбәпләре бар. Түбәндә өч гади сәбәп китерелә.

## 1. Галәмнең тәртиптә булуы.

Су буенда йөреп, комда сәгать табуны күз алдыгызга китерегез. Сәгатьнең үзе җыелганына ышанырсызмы? Сәгать комдан очраклы гына килеп чыккан дип нәтиҗә ясамас идегез. Барлык катлаулы эш өлешләре җиргә күмелгән материаллардан гына үсә алмады. Сәгатьнең ясаучысы булырга тиеш. Әгәр дә сәгать төгәл вакыт күрсәтсә, ясаучысы акыллы булырга тиеш дип нәтиҗә ясыйбыз. Табигый очраклар, эшли торган төгәл сәгать ясый алмый.

Җир шарына игътибар итик. Аның вакыты кояш тирәли әйләнүе шулкадәр төгәл җайга салынган ки, галимнәр кояш чыгу һәм кояш баю вакытын алдан бастыра алалар. Сәгатьнең төгәл вакытны күрсәтү өчен акыллы ясаучысы булган кебек үк, җирнең дә кояш тирәли төгәл әйләнүе өчен акыллы ясаучысы булырга тиеш. Бу үзе булырга мөмкинме?

Шул ук рәвешчә, без үзебездә һәм бөтен галәмдә тәртипне, төгәл законнарны һәм системаларны күргәндә, галәмнең тәртипкә салучысы булу рациональ түгелме? Бу "Тәртипкә салучы" иң яхшы итеп, Галәмдә тәртип китергән Зат - Аллаһның барлыгы белән аңлатыла.

## 2. Галәмнең башы.

Хәзерге фән галәмнең башы бар дигән нәтиҗәгә килә. Бу күптән түгел ачылган галәмнең киңәюенә нигезләнгән, һәм вакытны кире кайтара алу мөмкин булса иде, галәмнең башлангыч ноктасына кайтуын күрер идек. Галәмнең ничек башлануының өч мөмкин аңлатмасы бар. Яисә:

1. Галәм юклыктан барлыкка килгән.
2. Галәм үзе үзен барлыкка китергән.
3. Галәм кемнеңдер тарафыннан бар ителгән.

*Кеше тәҗрибәсе күрсәткәнчә, башлангычы булган нәрсә юклыктан бар булмый.*

Икенче аңлатмага килгәндә, гади логика безгә берәр нәрсә барлыкка килгәнче бернәрсә дә эшли алмый дип әйтә. Һәм бу өченче аңлатманы бердәнбер рациональ аңлатма итеп калдыра: кодрәтле, гыйлемле, хикмәтле зат - Аллаһ, галәмне барлыкка китерде.

CONTENTS





























Кайбер кешеләр: "Аллаһны кем барлыкка китерде?" - дип сорарга мөмкин. Барлыкка китерүче Аллаһ барлыкка китерелгән мәхлукатларыннан аерылып тора. Әгәр дә ул барлыкка китерелгән мәхлук белән бер булса, аңа шулай ук бар итүче кирәк булыр иде, һәм чиксез күләмдә бар итүчеләрнең булуына китерер иде, ә бу мөмкин түгел.

Барлыкка китерүче иләһ вакыттан һәм бу галәмнең физик матдәләреннән тыш. Аллаһ һәрвакыт булган һәм Аның башлангычы юк. Шуңа күрә, Аллаһны кем барлыкка китергән дигән сорау акылсызлык булыр.

## 3. Аллаһтан иңгән вәхи.

Ислам диненең китабы – Корьәннең, Аллаһ сүзе булуына ап-ачык дәлилләр бар. Түбәндә бу дәгъваны раслаучы сәбәпләрнең кыскача аңлатмасы бар:

*Әгәр дә Аллаһ кешелеккә туры юл күрсәтүче китап иңдерсә, без андый китапта һичшиксез Аллаһның барлыгына ачык дәлилләр күрербез.*

- Корьән 1400 ел элек иңдерелгән һәм ул вакыттагы кешеләргә билгеле булмаган, күптән түгел генә хәзерге фән тарафыннан ачылган күп фәнни фактларны үз эченә ала. Моның мисалларына түбәндәгеләр керә: су барлык тереклекнең асылы (Корьән, 21:30); киңәюче галәм (Корьән, 51:47); кояшның һәм айның аерым орбиталарга ия булулары (Корьән, 21:33).
- Корьәндә, ул вакыттагы кешеләргә билгеле булмаган күп тарихи фактлар, соңыннан дөреслеге исбатланган күп санлы фаразлар бар.
- Корьән төрле хаталардан, каршылыклардан азат.
- Элеккеге формасында сакланмыйча калган китаплардан аермалы буларак, Корьән гарәп телендә иңдерелеп, сүздән-сүз сакланып калган.
- Корьәннең гади, саф һәм универсаль хәбәрләре, кешенең Аллаһ турындагы ышануларына мөрәҗәгать итә.
- Корьән, тарихтан билгеле булганча, укый-яза белмәгән Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) иңдерелде. Шулай да, Корьәндә уникаль тел стиле бар, ул гарәп сөйләменең һәм лингвистик матурлыгының иң югары ноктасы буларак билгеле.

*Корьәннең уникаль һәм могҗизалы яклары өчен иң рациональ аңлатма – аның Аллаһтан булуы.*


CONTENTS



























# Кем ул иләһ?

"Аллаһ" - бердәнбер Хак иләһнең шәхси исеме. Башка бернәрсә дә Аллаһ дип атала алмый. Бу терминның, "иләһ" сүзеннән аермалы буларак (ягъни иләһләр), күплек саны юк.

"Аллаһ" исеменең уникаль рәвештә кулланылышы - Исламның бер Аллаһка ышануның сафлыгына басым ясавы.

> *"Сезнең иләһегез бер иләһ, аннан башка һичбер хак иләһ юк."*
> Коръән, 2:163

Исламның төп матурлыгы - Аллаһның камиллеген, бөеклеген һәм берлеген тулысынча тану. Бу Исламның Аллаһның исем-сыйфатлары хакындагы тәгълиматларында ачыктын-ачык чагыла.

## Аллаһ - Бердәнбер:

- Аллаһның тиңдәшләре дә, тиңнәре дә, көндәшләре дә юк.
- Аллаһның әтисе, әнисе, уллары, кызлары һәм хатыннары юк.
- Барлык гыйбадәтләргә бары тик Аллаһ кына лаеклы.
- Әгәр бердән артык иләһ булса, бу аларның көчләрендә яки хөкем итүләрендә җитешсезлекне күрсәтер иде, чөнки ул иләһләрнең арасында каршылык һәм узышу булыр иде.

## Аллаһ Кодрәтле:

- Аллаһ һәрнәрсәдән тулы хакимлек итә һәм һәрнәрсәгә көче җитә.
- Барысы да тулысынча Аллаһка буйсына.
- Аллаһка буйсыну Аның көчен арттырмый, һәм Аңа итәгатьсезлек Аның көчен дә киметми.

## Аллаһ Тәгалә Биек:

- Аллаһтан биегрәк яки Аның белән чагыштырырлык бернәрсә дә юк.
- Аллаһның сыйфатлары Аның мәхлукатының сыйфатларына охшамаган.
- Аллаһның бер өлеше дә беркемдә дә, бернәрсәдә дә юк.
- Аллаһ камил һәм Ул кешеләрне чикләүче факторлар белән чикләнмәгән, мисал өчен, кайбер диннәр әйтүенчә, галәмне барлыкка китергәннән соң җиденче көнне ял итү.

## Аллаһ Гадел һәм Рәхимле:

- Аллаһ гөнаһларны кичерү өчен үзен корбан итәргә тиеш түгел.
- Аллаһ һәркемне үз эшенә карап хөкем итә һәм һәркем үз эше өчен җавап бирә.
- Кешеләр Аллаһның ризалыгына иман һәм изге гамәл белән ирешә алалар, ә раса, байлык яки иҗтимагый дәрәҗәләре белән түгел.


CONTENTS



























# Гайсәнең табигате.

*Исламда иләһ төшенчәсен аңлатканда, Гайсәнең табигате турында киң таралган буталчыкларны һәм дәгъваларны исәпкә алып, Гайсәнең статусы турында сөйләшү мөһим.*

Христианнарның күбесе "Гайсә – ул иләһ", ягъни ул - Аллаһның җирдә гәүдәләнеше һәм Аллаһ кеше формасын алган дип әйтәләр.

Ләкин, изге язмалар буенча, Гайсә туган, ашаган, йоклаган, намаз укыган һәм белемнәре чикләнгән, һәм бу барлык сыйфатлар Аллаһка туры килми. Аллаһ камиллек сыйфатларына ия, ә кешедә киресенчә, андый камиллек юк. Шулай итеп, ничек берьюлы ике капма-каршы нәрсә бер вакытта җыелырга мөмкин? Бу акылга сыя торган түгел.

Ләкин кайбер кешеләр: "Әгәр дә Аллаһ һәрнәрсәне эшли алса, нигә ул кеше була алмый?" Төшенчә буенча, иләһ аңа туры килми торган эшләрне эшләми, шуңа күрә иләһ кеше булып, кеше сыйфатларын үз өстенә алса, ул, әлбәттә, иләһ булмас иде.

Моннан тыш, изге язмаларда Гайсә, Аллаһның бәндәсе һәм Аллаһтан аерым зат булган рәвештә, сөйләшә һәм үзен тота. Мәсәлән, Гайсә "ләкин хәзер сез мине үтерергә омтыласыз, ә мин сезгә Аллаһтан ишеткән хакыйкатьне сөйли торган кеше генә". [Яхъя 8:40].

Христианнарның күбесе шулай ук "Гайсә - Аллаһ Улы" дип әйтәләр, ләкин без үз-үзебездән сорарга тиеш, бу нәрсәне аңлата?

Әлбәттә, Аллаһ физик улы булудан ерак. Киресенчә, без "Аллаһ Улы" төшенчәсенең символик рәвештә иң элек Библия телләрендә "изге кешеләр" хакында кулланылганын күрәбез. Бу Иске Васыятьтә Давыт, Сөләйман һәм Израиль кебек күп изге кешеләр хакында кулланыла, ә Гайсә өчен генә түгел.

Мисал өчен, "... Израиль - минем беренче улым" (Чыгыш, 4:22).

Ислам ышануы чын Гайсәнең кем икәнен аңлата, шул ук вакытта Аллаһ һәм Аның Бөеклеге турында саф ышануны саклый. Гайсә Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырган хөрмәтле пәйгамбәр иде.

*“Аллаһка бала алу килешми. Ул (балалы булудан) пакь!”*
Коръән, 19:35


CONTENTS






























## Бердәнбер Аллаһ кына гыйбадәткә лаеклы.

“Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә тиңдәш итмәгез.” Коръән, 4:36

Ислам, барлык гыйбадәтләр Аллаһка гына сарыф ителергә тиешлеген өйрәтә. Башка бернәрсә дә гыйбадәткә лаеклы түгел: сынымнар, каберләр, кояш, ай, хайваннар, пәйгамбәрләр, изгеләр, фәрештәләр, руханилар яки дин галимнәре түгел. Бу әйберләрнең барысы да юктан бар ителгән һәм чикләнгән, димәк камил түгел, ә бердәнбер Аллаһ абсолют камиллек иясе.

## Аллаһка турыдан-туры тиңдәшләрсез гыйбадәт кылу.

Аллаһка бернинди тиңдәшчеләр яки арадашчылар кирәк түгел. Һәркемнең һәрвакыт Аллаһка гыйбадәт кылу мөмкинлеге бар, чөнки Ул Аны мактаучы һәм ялваручыларны ишетә. Аллаһка арадышчылар аша гыйбадәт кылу (мәсәлән, потлар, сынымнар яки башка арадашчылар) Аллаһның берлегенә һәм Ул үзе генә лаеклы булган гыйбадәтнең сафлыгына зыян китерү дип санала.

## Барлык пәйгамбәрләр дә Аллаһка гыйбадәт кылырга чакырдылар.

"Хакыйкатьтә без (Аллаһ), һәрбер халыкка Рәсүл җибәрдек: "Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз һәм ялган иләһләрдән сакланыгыз ". (Коръән, 16:36).

Мөселманнар Аллаһ җибәргән барлык пәйгамбәрләргә ышаналар. Бу пәйгамбәрләргә Адәм, Нух, Ибраһим, Муса, Гайсә һәм Мөхәммәд керә. Алар барысы да бер үк максат белән килделәр - үз халкын бер Хак Аллаһка ышанырга һәм гыйбадәт кылырга чакыру.

## Тормышның максаты - Аллаһка гыйбадәт кылу.

Тормышның төп максаты - Аллаһның бөеклеген тану, аның белән туры бәйләнеш урнаштыру һәм Аңа гына гыйбадәт кылу. Исламда гыйбадәт төшенчәсе дога кылу һәм ураза тоту кебек йолалар белән генә чикләнми, ул күркәм әхлаклы, намуслы булу, гаделлек урнаштыру, сабыр булу һәм мохтаҗларга булышу кебек Аллаһ яраткан һәм риза булган эшләрне үз эченә ала.

Ахырда, Исламның нигезе - чиксез кодрәтле Аллаһның бердәнберлегенә, ул һәрнәрсәне барлыкка китерүче һәм хуҗасы, барлык камил сыйфатларга ия һәм бердәнбер Үзе генә гыйбадәткә лаеклы булуына ышану. Безнең бу тормышта һәм ахирәттә уңышка ирешүебез шушыны булдыруда ята.


CONTENTS


ИСЛАМГА КЕРЕШ
МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР
МӘРЬЯМ УЛЫ ГАЙСӘ: АЛЛАҺНЫҢ РАСУЛЕ.
ИСЛАМДА ИЛӘҺ ТӨШЕНЧӘСЕ
КОРЪӘН Кешелеккә соңгы вәхи.
ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ НИНДИ?
Ислам турында ялгыш карашлар.
ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ.
КОРЪӘННЕҢ ФӘННИ МОГҖИЗАЛАРЫ
ҮЛЕМ ҺӘМ АХИРӘТ.


# КОРЪӘН

## Кешелеккә соңгы вәхи.

TATARI (05/10) القرآن FREE COPY




جمعية دار البر
Dar Al Ber Society
www.daralber.ae

الإمارات
THE EMIRATES

Your Path To Peace..

مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام

تصريح رقم:
(2017/139)

دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري
Islamic Affairs & Charitable Activities Department

www.islamicic.com

CONTENTS































# НӘРСӘ УЛ КОРЪӘН?

## Аллаһ сүзе.

Коръән - ул Җәбраил фәрештә аша, Мөхәммәд пәйгамбәргә, Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын, иңдерелгән Аллаһның сүзе.

*“Китапның иңдерелүе - бөек һәм хикмәт иясе булган Аллаһтан.”*

Коръән, 39:1

## Кешелек өчен туры юл.

*Кыскача, Коръән ул - “кешеләр өчен һидәят, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, һәм хакны ялганнан аеручы китап булып тора”*

Коръән, 2:185

Коръән ул - кешелек өчен дөреслек белән хатаны аерып күрсәтүче чыганак, һәм аннан башка, һичшиксез, кеше адашу даласында һәлак булачак.

## Соңгы вәхи.

Коръән ул - Аллаһ Тәгалә иңдергән соңгы китап. Ул элекке мөкаддәс китапларның кайбер өлешләрендә, аз рәвештә калган хакыйкатьнең дөреслеген исбатлый һәм раслый. Һәм бүгенге көндә кешеләр кулында булган ул мөкаддәс китапларга ягылган ялганнарны һәм өстәмәләрне кире кага һәм дөресли.

“Әй, китап бирелгән кешеләр (яһүдләр), үзегездә булган(Тәүратны) раслаучы, Без иңдергән Коръәнгә иман китерегез (ышаныгыз)” (Коръән, 4:47).

# КОРЪӘН НИЧЕК ИҢГӘН?

Коръән Мөхәммәд пәйгамбәргә, Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын, гарәп телендә генә иңгән, шуңа да карамастан, Коръәннең мәгънәләре төрле телләргә тәрҗемә ителгән.

Коръән тулаем китап буларак, бер иңүдә иңмәде, бәлкем вәхи 23 ел дәвам итте. Шуңа күрә, Коръәнне дөрес аңлау өчен, аятьләрнең нинди хәлләрдә иңүен белү зарури булып тора, югыйсә аның тәгълиматлары хаталы аңлашылырга мөмкин.

CONTENTS
































# АНЫҢ АЛЛАҺТАН БУЛУЫ

## Аллаһ Тәгаләнең аны саклавы.

Коръән озын вакыт дәвамында кулланылып та, иңгән көнендә кебек үк сакланган, бердәнбер дини мөкатдәс текст. Аның иңүенә 1400 елдан артык вакыт үтте, шулай да аңа бернәрсә өстәлмәгән дә, киметелмәгән дә, һәм төзәтелмәгән дә.

*“Һичшиксез, Коръәнне Без иңдердек һәм Без аны (үзгәртелү, югалудан) саклыйбыз”*

Коръән, 15:9

Коръән язылган хәлендә генә түгел, бәлкем ир-атлар, балалар һәм хатын-кызларның йөрәкләрендә сакланган. Бүгенге көндә, миллионлаган кешеләр Коръәнне башыннан алып, ахырына хәтле яттан беләләр.

## Фәнни могҗиза.

Коръән фәнгә каршы килми, бәлки аның хакыйкатьләрен раслый гына. Моның иң ачык мисалларыннан күп кенә Коръән аятьләренең төрле фәнни өлкәләрдә булган нечкәлекләрне төгәл итеп тасвирлавы. Мисал өчен, эмбриология, метеорология, астрономия, геология һәм океанография. Фән галимнәре, аның тасвирлавларын, җиденче гасыр китабы өчен, искиткеч төгәл дип саныйлар.

*“Аларга офыкларда һәм үз нәфесләрендә аятьләребезне күрсәтәчәкбез дә, алар беләчәкләр ки, ул (Коръән) хак ”*

Коръән, 41:53

Хакыйкатьтә, Коръәндә әйтеп үтелгән күп кенә фәнни ачышлар, технологик прогресс аша, күптән түгел генә беленде әле. Түбәндәгеләрне уйлап кара әле:

- Коръән, кеше эмбрионының үсешен төгәл тасвирлап бирә, ә бит бу нечкәлекләр, фәнни берләшмә өчен күптән түгел генә билгеле булды.
- Фән, ике диңгез очрашып, һәрберсе үзенең температурасын, тыгызлыгын һәм тозлылыгын саклаган хәлдә, араларында киртә барлыгын ачыш ясады.

Ә Аллаһның бу аятьләре ап-ачык итеп Коръәндә 1400 ел элек әйтеп үтелгән иде

CONTENTS































# НИЧЕК БЕЛӘ АЛАМ?

## Бердәнберлек (уникальлек).

Коръән иңгәннән бирле, аның кебек үзенең матурлыгында, сөйләмендә, гүзәллегендә, хикмәтендә һәм башка камил сыйфатларында, беркем бер генә сүрә дә китерә алмады.

Мөхәммәд пәйгамбәргә, Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын, ышанмаганнар Коръән теле булган, гарәп телендә матур сөйләмле булуларына карамастан, бу сынауда уңышсызлыкка ирештеләр, һәм бүгенге көнгә кадәр дә, беркем дә бу сынауга җавап бирә алмады.

*“Әгәр дә колыбызга иңдергән нәрсәдән (Коръәннән) шикләнсәгез, сез дә аңа охшаш берәр сүрә (үйлап табып) китерегез һәм үзегезгә бу эштә Аллаһтан башка шаһитларыгызны , (ярдәмчеләрегезне) чакырыгыз, әгәр (Расүлемнең Коръәни Кәримне үзе үйлап чыгарган дигән фикерегезгә) туры кешеләр булсагыз!”*

(Коръән, 2:23)

## Анда каршылык булмау.

Кешеләр нәрсәдер язганда, һичшиксез, грамматика-орфография ягыннан яки сүзләрендә бер-берсенә каршылык булып, яки дөрес булмаган нәтиҗәләр ясап, яки башка төр хаталар ясыйлар.

Ә Корьәндә бернинди каршылык та юк, булсын ул фәнни аңлатмалар, эмбриология, геология, космология, тарихи фактлар һәм вакыйгалар.

*“Әллә алар Коръән турында фикерләмиләрме? Әгәр ул (Коръән) Аллаһтан булмаса, анда (мәгънәләр туры килмәү кебек) бик күп каршылыклар табарлар иде”*

Коръән, 4:82

## Мөхәммәд аны яза алмый идеме?

Мөхәммәд пәйгамбәрнең, Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын, укый да, яза да белмәгәнлеге тарихта билгеле. Ул бер өлкәдә дә белем алмаган, шуңа күрә дә фәнни, тарихи нечкәлекләрне һәм бу китапның искиткеч әдәби матурлыгын аңлата алмас иде. Коръәндә килгән, элекке халыкларның һәм цивилизацияләрнең тарихи риваятьләренең төгәллеге кеше яза алмас дәрәҗәдә бөек.

*“Бу Коръән уйдырма бернәрсә түгел, Аллаһтан башка берәү тарафыннан да түгел”*

Коръән, 10:37

CONTENTS






# ВӘХИ (КОРЪӘН ИҢҮНЕҢ) МАКСАТЛАРЫ.

## Бердәнбер хак иләһкә ышану.

*Сезнең иләһегез бер иләһ, аннан башка һичбер хак иләһ юк, Рәхимле, Шәфкатьле."* ***(Корьән, 2:163).***

Корьәндә килгән иң мөһим тема ул бердәнбер хак Аллаһка ышану. Аллаһ Тәгалә безгә Аның тиңдәше дә, улы да, охшашы да булмавы турында хәбәр итә, Аннан башка беркем дә гыйбадәткә лаеклы түгел. Бернәрсәне дә Аллаһ белән чагыштырып булмый, һәм Аның бер мәхлугы да Аңа охшамаган. Шулай ук Корьән Аллаһ Тәгаләгә кешеләрнең сыйфатларын һәм кимчелекләрен нисбәт итүне кире кага.

## Барлык ялган иләһләрне кире кагу.

"Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә тиңдәш итмәгез." (Корьән, 4:36).

Бердәнбер Аллаh Үзе генә гыйбадәткә лаеклы булгач, димәк Аллаһтан башка нәрсәләрне һәм ялган иләһләрне кире кагу тиешле була. Шулай ук Корьән Аллаһтан башка ниндидер шәхескә яки әйбергә иләһлек сыйфатларын бирүне кире кага.

## Элекке заман кыйссаларын сөйләү.

Корьән файдалы сабаклардан торган күп кенә риваятьләрне үз эченә алган. Аларның арасында Адәм, Нух, Ибраһим, Гайсә һәм Муса кебек элекке пәйгамбәрләрнең хакыкый кыйссалары килә. Бу кыйссалар турында Аллаһ Тәгалә болай дип әйтә:

*"Аларның кыйссаларында акыл ияләре өчен (зур) гыйбрәт бар"* ***Корьән, 12:111***

## Безгә Кыямәт көнен искә төшерү.

Бу күркәм китап безгә, барысы да үлемне татыячак һәм һәр эше һәм сүзе өчен хисап тотачагын искә төшерә:

*"Без Кыямәт көне өчен мизаннарны куячакбыз. Бер генә җан да золым кылынмас (рәнҗетелмәс)"* ***Корьән, 21:47***

## Хакыйкый тормыш рәвешен чынга ашыру.

Барысыннан да мөһимрәге, Корьән кешенең тормыш максаты бердәнбер Аллаһка гыйбадәт кылу икәнлеген өйрәтә. һәм кеше үз тормышын Аллаh риза була торган хәлдә яшәргә тиеш. Гыйбадәт төшенчәсе Исламда, Аллаh яраткан һәм риза булган бар эшләрне һәм сүзләрне үз эченә ала, булсын алар ачык яки яшерен. Шулай итеп, мөселман кешесе Аллаh Тәгалә кушканнарны үтәп, Аңа гыйбадәт кылган булыр һәм тормыштагы максатын чынга ашырыр.


CONTENTS





























Һәм түбәндә Коръәннән гыйбадәткә мисаллар:

**Намаз.** “Әй, иман китергән бәндәләр! Рөкүгъ һәм сәҗдә кылыгыз, Раббыгызга гыйбадәт кылыгыз, һәм игелек эшләгез. Бәлкем, сез уңышка ирешерсез” (Коръән, 22:77).

**Сәдака.** “Һәм (сезгә биргән ризыклардан бер өлешен) үзегез өчен яхшырак булган шәкелдә сарыф итегез. Кем дә кем үзенең комсызлык хирысыннан курка, шулар уңышка ирешүчеләр” (Коръән, 64:16).

**Әманәт.** “Үзегез белгән хәлдә хакыйкатьне яшереп, хакны ялган белән бутамагыз” (Коръән, 2:42).

**Тыйнаклык.** “Иманлы ирләргә әйт, (хәрамга караудан) күз карашларын түбән төшерсеннәр һәм җенес әгъзаларын сакласыннныр”,“Иманлы хатыннарга әйт, (хәрамга караудан) күз карашларын түбән төшерсеннәр һәм җенес әгъзаларын сакласыннныр” (Коръән, 24:30-31).

**Шөкерле (рәхмәтле) булу.** “Аллаһ сезне берни белмәгән хәлегездә аналарыгызның карыннарыннан чыгарды, сезгә колаклар, күзләр һәм (аң-зиһен үзәге булган) күңелләр бирде. Бәлкем, сез шөкер итәрсез.” (Коръән, 16:78).

**Гадел булу.** “Әй, иман китергәннәр! Гаделлекне нык яклаучылар һәм Аллаһ (ризалыгы) өчен шаһитлык кылучылар булыгыз, хәтта үз-үзегезгә яки ата-ана һәм якыннарыгызга каршы булса да” (Коръән, 4:135).

**Сабыр итү.** “Сабыр ит. Дөреслектә, Аллаһ изгелек кылучыларның әҗерләрен юкка чыгармый” (Коръән, 11:115).

**Изгелек эшләү.** “Иман китергән һәм изге гамәлләр кылганнарга Аллаһ мәгъфирәт һәм зур әҗер вәгъдә итте” (Коръән, 5:9).

## Йомгаклау.

Кыскача, Коръән кешеләрне ничек итеп бердәнбер хак иләһкә гыйбадәт кылырга, һәм шул рәвешле тормыштагы максатларын чынга ашырырга, һәм ике дөнья бәхетенә ирешергә өйрәтә.

*“Һичшиксез, Без Китапны синә кешеләр өчен хак белән иңдердек. Кем дә кем (аның белән гамәл кылып) һидәять тапса, үз файдасына. Кем дә кем (ул Китап кушканча гамәл итмичә, туры) юлдан язса, үз зарарына булыр”*

Коръән, 39:41

HOTLINE
+971 56 204 2045
islamicicdxb
islamicic.com
info@islamicic.com
+971 4 355 5223
DOWNLOAD TATARI FLYER
www.iicdxb.com/tatari

CONTENTS


- ИСЛАМГА КЕРЕШ
- МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР
- МӘРЬЯМ УЛЫ ГАЙСӘ: АЛЛАҺЫҢ РАСУЛЕ.
- ИСЛАМДА ИЛӘҺ ТӨШЕНЧӘСЕ
- КОРЪӘН Кешелеккә соңгы вахи.
- ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ НИНДИ?
- Ислам турында ялгыш карашлар.
- ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ.
- КОРЪӘННЕҢ ФӘННИ МОГҖИЗАЛАРЫ
- ҮЛЕМ ҺӘМ АХИРӘТ.


# ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ НИНДИ?

TATARI (06/10) الغاية من الحياة FREE COPY

**Мин каян килдем? Нигә мин монда? Мин кая барам?**


Dar Al Ber Society
www.daralber.ae

الإمارات
THE EMIRATES

Your Path To Peace..

مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام

تصريح رقم: (2017/139)

دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري
Islamic Affairs & Charitable Activities Department

www.islamicic.com


CONTENTS




























# Тормышның максаты нинди?

Тормыш максатыбыз турында уйлаганда, беренче сорауларның берсе: "Без каян килдек?"

Безнең бу тормышта барлыгыбыз табигый очракларга нигезләнгәнме, яисә хикмәтле бар итүче бармы? Бар итүченең барлыгын тану - тормыштагы чын максатыбызны аңлау өчен беренче адым. Бар итүчегә ышану өчен бик күп логик һәм рациональ сәбәпләр бар. Өч сәбәп түбәндә кыскача искә алына.

## 1. Галәмнең башы.

Аллаһның барлыгын күрсәтүче беренче дәлил галәмнең килеп чыгышын аңлау белән бәйле.

*Кайберәүләр: "Аллаһны кем барлыкка китерде", - дип сорарга мөмкин. Барлыкка Китерүче Аллаһ барлыкка китерелгән мәхлукларыннан аерылып тора. Аллаһ мәңгелек, һәрвакыт булган һәм башы юк. Шуңа күрә, Аллаһны кем барлыкка китергән дигән сорау акылсыз.*

Чүлдә йөреп, сәгать табуны күз алдыгызга китерегез. Без беләбез, сәгать пыяла, пластик һәм металлдан тора. Пыяла комнан, пластмасса нефтьтән, һәм метал җирдән алынган - бу компонентларның барысы да чүлдә. Сәгать үзе барлыкка килгәненә ышанырсызмы? Кояш балкып, шуннан соң җил искән, аннары яшен сугып, нефть өскә чыгып, ком һәм металл белән кушылган, һәм миллионнарча ел дәвамында сәгать очраклы рәвештә җыелган дип ышанып идегезме?

Кеше тәҗрибәсе һәм гади логика безгә әйтә, башлангычы булган әйбер бернәрсәсез дә барлыкка килми, һәм үз-үзен дә булдыра алмый. Шуңа күрә, иң рациональ аңлатма - галәмне югары "зат" барлыкка китергән. Бу "зат" көчле һәм гыйлемле булырга тиеш, чөнки ул бөтен галәмне барлыкка китерде һәм аны идарә итүче "фән законнарын" барлыкка китерде. Без шулай ук бу "зат" вакыт һәм урын белән чикләнмәгән дип ышана алабыз, чөнки вакыт, урын һәм матдә галәм барлыкка килгәндә башланган. Бу сыйфатларның барысы да галәмне барлыкка китерүче Аллаһ төшенчәсен тәшкил итә. Һәм бу галәм чикле һәм башы бар дигән нәтиҗәгә килгән, хәзерге фән белән туры килә.

CONTENTS

































## 2. Галәмнең камиллеге.

Гыйлемле бар итүченең барлыгын күрсәтүче икенче дәлил - безнең катлаулы галәмнең тәртибе һәм камил балансы.

Галәмдәге күп үзенчәлекләр аның тормышны тәэмин итү өчен махсус эшләнгәнен ачык күрсәтәләр, мәсәлән, җирнең кояштан ераклыгы, җир кабыгының калынлыгы, җир әйләнүенең тизлеге, атмосферада кислород проценты һәм хәтта җирнең омтылышы. Әгәр дә бу үлчәүләр хәзергедән бераз аерылып торса, тормыш була алмас иде.

Сәгатьнең төгәл вакытны саклар өчен акыллы житештерүчесе булган кебек, шулай ук җир дә кояш тирәсендә төгәл вакытны саклап калсын өчен гыйлемле житештерүчесе булырга тиеш. Бу үзеннән үзе булырга мөмкинме?

Без үзебездә һәм бөтен галәмдә тәртипне, төгәл законнарны һәм системаларны күргәндә, аларны тәртипкә салучысы булырга тиеш дигән җавап рациональ булмасмы? Бу "тәртипкә салучы" - бу тәртипне бар иткән Аллаһның барлыгы белән иң яхшы рәвештә аңлатыла.

## 3. Аллаһтан вәхи.

Аллаһның барлыгын күрсәтүче өченче дәлил - Аллаһ үзенең барлыгына билге итеп кешеләргә җибәргән хакыйкый вәхи. Ислам китабы, Коръән - Аллаһның сүзе булуына ап-ачык дәлилләр бар. Түбәндә бу дәгъваны раслаучы сәбәпләр турында кыскача мәгълүмат.

*Әгәр дә Аллаһ кешеләргә туры юл күрсәтү өчен китап җибәргән икән, анда һичшиксез Аллаһның барлыгына ачык дәлилләр булачак.*

- Коръән 1400 ел элек иңдерелгән һәм ул вакыттагы кешеләргә билгеле булмаган, күптән түгел генә хәзерге фән тарафыннан ачылган күп фәнни фактларны үз эченә ала. Моның мисалларына түбәндәгеләр керә: су барлык тереклекнең асылы (Коръән, 21:30); киңәюче галәм (Коръән, 51:47); кояшның һәм айның аерым орбиталарга ия булулары (Коръән, 21:33).
- Коръәндә, ул вакыттагы кешеләргә билгеле булмаган күп тарихи фактлар, соңыннан дөреслеге исбатланган күп санлы фаразлар бар.
- Коръән 23 ел дәвамында әкренләп иңүенә һәм төрле темаларны яктыртуына карамастан, ул хаталардан, каршылыклардан азат.
- Коръән, асыл формасында сакланып калмаган китаплардан аермалы буларак, гарәп телендә иңеп, сүздән-сүз сакланып калган.
- Коръәннең гади, саф һәм универсаль хәбәрләре, кешенең Аллаһ турындагы ышануларына мөрәҗәгать итә.

CONTENTS






• Коръән кешеләргә тирән йогынты ясый, аны Корънәнең татлылыгын йөрәге белән зәвык иткән кеше генә сизә.

• Коръән, тарихтан билгеле булганча, укый-яза белмәгән Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) иңдерелде. Шулай да, Коръәндә уникаль тел стиле бар, ул гарәп сөйләменең һәм лингвистик матурлыгының иң югары ноктасы буларак билгеле.

Корънәнең уникаль һәм могҗизалы яклары өчен иң рациональ аңлатма – аның Аллаһтан булуы.

## Аллаһ туры юлга күндерүче.

Хикмәтле Бар итүче тарафыннан яралтылганлыгыбызны таныгач, безгә тормышыбыздагы максатыбыз турында хәбәр итерләргә тиешлеген аңларбыз. Аллаһ бездән нәрсә теләгәнен без ничек белә алабыз? Без хаталы яшибезме, яисә безгә куелган максатыбызны үтибезме? Яисә без башкаларга ияреп "агым белән барабызмы"?

> *Гайсә, башка пәйгамбәрләр кебек үк, могҗизалар күрсәтте һәм кешеләрне бердәнбер Хак Аллаһка табынырга чакырды*
>
> Коръән 19:36

Юк. Аллаһ безнең максатыбыз турында хәбәр итәр өчен пәйгамбәрләр җибәрде һәм китаплар иңдерде.

Аллаһ меңләгән пәйгамбәрләрне, ким дигәндә һәр халыкка берне генә булса да җибәрде, барысы да бер максат белән килделәр: бердәнбер Аллаһка табыну һәм аның туры юлына иярү. Алар арасында Адәм, Нух, Ибраһим, Муса, Гайсә һәм Мөхәммәд (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) бар.

Пәйгамбәрләр чылбырында соңгысы - Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) намуслы, гадел, шәфкатьле, мәрхәмәтле һәм батыр кешенең камил үрнәге булды. Ул Аллаһтан соңгы вәхи (китап) белән, шул китапның тәгълиматларын ничек тормышка ашырырга кирәклеген күрсәтү өчен җибәрелде.

Коръән – туры юл китабы. Ул безнең барлыгыбызның максатын; кем ул Аллаһ; Аллаһ яраткан һәм сөймәгән гамәлләрне; Пәйгамбәрләрнең кыйссаларын һәм алардан чыккан файдалы дәресләрне; Җәннәт, Җәһәннәм һәм Кыямәт көне турындагы хәбәрләрне һәм башка күп кенә төшенчәләрне аңлата.

Коръән Аллаһ турында дөрес булмаган фикер-карашларны ачыклый, мәсәлән, Гайсәнең табигате, роле һәм аны Аллаһ Тәгалә белән чагыштыру.


CONTENTS
























# Гайсәнең табигате.

*Исламда илаһ төшенчәсен аңлатканда, Гайсәнең табигате турында киң таралган буталчыкларны һәм дәгъваларны исәпкә алып, Гайсәнең статусы турында сөйләшү мөһим.*

Кайбер христианнар "Гайсә – ул илаһ", ягъни ул - Аллаһның җирдә гәүдәләнеше һәм Аллаһ кеше формасын алган дип әйтәләр.

Ләкин, изге язмалар буенча, Гайсә туган, ашаган, йоклаган, намаз укыган һәм белемнәре чикләнгән, һәм бу барлык сыйфатлар Аллаһка туры килми. Аллаһ камиллек сыйфатларына ия, ә кешедә киресенчә, андый камиллек юк. Шулай итеп, ничек берьюлы ике капма-каршы нәрсә бер вакытта җыелырга мөмкин? Бу акылга сыя торган түгел.

Ләкин кайбер кешеләр: "Әгәр дә Аллаһ һәрнәрсәне эшли алса, нигә ул кеше була алмый?", - дип сорыйлар. Төшенчә буенча, илаһ аңа туры килми торган эшләрне эшләми, шуңа күрә илаһ кеше булып, кеше сыйфатларын үз өстенә алса, ул, әлбәттә, илаһ булмас иде.

Моннан тыш, изге язмаларда Гайсә, Аллаһның бәндәсе һәм Аллаһтан аерым зат булган рәвештә сөйләшүен һәм үзен тотуын күрербез.

Мәсәлән, Гайсә «сәҗдәгә йөзтүбән китеп дога кылды» [Маттай(Матвей), 26:39]. Әгәр Гайсә илаһ булса иде, илаһ булган зат сәҗдәгә йөзтүбән китеп дога кылырмы? Ул кемгә дога кылыр иде?

Христианнарның күбесе шулай ук "Гайсә - Аллаһ Улы" дип әйтәләр, ләкин без үз-үзебездән сорарга тиеш, бу нәрсәне аңлата?

Әлбәттә, Аллаһ физик улы булудан ерак. Киресенчә, без "Аллаһ Улы" төшенчәсенең символик рәвештә иң элек Библия телләрендә "изге кешеләр" хакында кулланылганын күрәбез. Бу Иске Васыятьтә Давыт, Сөләйман һәм Израиль кебек күп изге кешеләр хакында кулланыла, ә Гайсә өчен генә түгел.

Мисал өчен, "... Израиль - минем беренче улым" (Чыгыш, 4:22).

Ислам ышануы чын Гайсәнең кем икәнен аңлата, шул ук вакытта Аллаһ һәм Аның Бөеклеге турында саф ышануны саклый. Гайсә Аллаһка гына гыйбадәт кылырга чакырган хөрмәтле пәйгамбәр иде.

*“Аллаһка бала алу килешми. Ул (балалы булудан) пакь!”*
Коръән, 19:35

CONTENTS






## Алайса ... Нигә мин монда?

Барысы да безнең күз, колак, ми һәм йөрәк кебек тән өлешләренең максатлары барлыгын таныйлар. Алайса, кеше барлыгының да максаты бар дигән мәгънә түгелме соң?

Аллаһ Тәгалә безне максатсыз адашырга яки төп инстинктларыбызны һәм теләкләребезне тормышка ашырырга яралтмады. Киресенчә, безнең максат югарырак – Аллаһның барлыгын тану һәм Аңа табыну, шулай итеп без барлыкка китерүчебезнең туры юлы буенча яшәрбез. Бу туры юл безгә барлык өлкәләрдә дә уңышлы һәм мөбарәк тормыш алып барырга мөмкинлек бирә. Туры юл Аллаһка тәвәккәллек(таяну), намаз уку, ураза тоту, шулай ук җәмгыять өчен файдалы гамәлләр эшләү, күршеләргә яхшы булу, гаиләңне кайгырту, намуслы булу, хайваннар турында кайгырту кебек эшләрне үз эченә ала.

Аллаһ безгә башкаларга табынуны тыя (кемнәр генә булуына карамастан, сыннар, кояш, ай, изгеләр, руханилар, хәтта пәйгамбәрләр). Аңа бернинди иптәшләр, арадашчылар кирәк түгел. Һәркем һәрвакыт турыдан-туры Аллаһка гыйбадәт кыла ала.

Аллаһ бу тормышны сынау дип тасвирлый, һәм кешеләр төрлечә сынала. Без үзебез белән нәрсә булганын контрольдә тота алмыйбыз, ләкин без үзебезнең реакциябезне контрольдә тота алабыз. Авырлыклар вакытында сабыр итү, бирелгән нигъмәтләр өчен рәхмәтле булу - Аллаһка якынлашу һәм Җәннәткә ирешү сәбәбе булып тора.

Әгәр дә без Аллаһка көферлекне сайласак һәм Аның әмерләрен санга сукмасак, безгә җәһәннәм утында каты җәза булачагы турында кисәтү булды.

## Алайса ... мин хәзер нишләргә тиеш?

Акылны куллану, Аллаһның барлыгын күрсәтүче дәлилләр белән танышу һәм Аның туры юлы буенча яшәү – менә монда кешенең иманы сынала. Бу Аллаһның боерыкларына буйсынып эшләнә, гарәпчә "мөселман" булырга дигән сүз.

Бердәнбер барлыкка китерүче Аллаһ, Ислам белән танышуны, тарихына, ышануына яки хәзерге торышына карамастан, һәркемгә уңайлы итте. Шуңа күрә, теләсә кем ышанып, түбәндәге шаһитлекне әйтеп мөселман була ала:

"Мин Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы иләһ юклыгына шаһитлек, һәм Мөхәммәд Аллаһның Рәсүле булуына шаһитлек бирәм."

CONTENTS

ИСЛАМГА КЕРЕШ
МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын)
МӘРЬЯМ УЛЫ ГАЙСӘ: АЛЛАҺНЫҢ РАСУЛЕ.
ИСЛАМДА ИЛӘҺ ТӨШЕНЧӘСЕ
КОРЪӘН Кешелеккә соңгы вәхи.
ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ НИНДИ?
Ислам турында ялгыш карашлар.
ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ.
КОРЪӘННЕҢ ФӘННИ МОГҖИЗАЛАРЫ
ҮЛЕМ ҺӘМ АХИРӘТ.

# Ислам турында ялгыш карашлар.

TATARI (07/10) مفاهيم خاطئة حول الإسلام FREE COPY

Ислам турында чыннан да син нәрсә беләсең?

Dar Al Ber Society
www.daralber.ae
الإمارات THE EMIRATES
Your Path To Peace..
مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام
تصريح رقم: (2017/139)
دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري
Islamic Affairs & Charitable Activities Department
www.islamicic.com

CONTENTS




Ислам - дөньядагы иң зур диннәрнең берсе булуына карамастан, ләкин ул шулай ук күп кенә кешеләр дөрес аңламаган диннәрнең берсе дә. Моның сәбәпләре төрле - шулардан сәяси, икътисадый, икейөзле массакүләм мәгълүмат чаралары яки "бүтәннәрдән" курку, шулай ук алар арасында Ислам турында таралган ялгыш карашлар да. Һәм Исламны һәм мөселманнарны дөрес аңлау ачкычы – шул стереотипларга каршы тору һәм һәр ситуацияне Ислам тәгълиматларының дөрес чыганаклары аша тикшерү.

## Беренче ялгыш караш – **“Мөселманнар изгелекне һәм яхшы кыйммәтләрне мөселман булмаган кешеләр белән уртаклашмыйлар”.**

Кайбер кешеләр ислам кыйммәтләренең кешеләр килешенеп кабул иткән кыйммәтләргә туры килмәвен әйтәләр. Мондый дәгъвалар хакыйкатьтән һәм гаделлектән ераклар. Чөнки мөселманнар асыл һәм дөньякүләм кыйммәтләрне кадерлиләр:

*“Сезнең иң яхшыларыгыз – әдәп-әхлагы белән иң күркәм булганыгыз.” (Әхмәд, 24204) - Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ.*

- намуслы һәм гадел булу.
- биргән вәгъдәне үтәү.
- башкаларны билгеле бер дингә ышанырга мәҗбүр итмәскә.
- ата-аналарны, туганнарны, күршеләрне, өлкәннәрне хөрмәт итү.
- хәйриялек, юмарт булу, фәкыйрь һәм мохтаҗларны кайгырту.
- күршесе турында кайгырту.
- ялганламаска, алдамаска, беркемне дә сүкмәскә һәм гаебен сөйләмәскә.

Мөселманнардан җәмгыятькә уңай өлеш кертергә һәм һәрвакыт үзләрен иң югары әхлакта тотарга һәм иң яхшы гамәлләр кылырга таләп ителә.

## Икенче ялгыш караш – **“Мөселманнар “Аллаһ” дип аталган яңа бер иләһкә табыналар”.**

“Аллаһ” сүзе – иләһ сүзен аңлатып, бердәнбер Аллаһны белдерә торган бай мәгънәле гарәп сүзе. Шулай ук гарәп телендә сөйләшүче христианнар һәм яһүдләр дә табына торган иләһләренә Аллаһ дип мөрәҗәгать итәләр.

*Мөселманнар аларга кадәр булган Нух, Ибраһим, Муса һәм Гайсә пәйгамбәрләр табынган кебек үк бер Аллаһка табыналар.*

Ләкин, мөселманнар, яһүдләр һәм насаралар бер үк Аллаһка (барлыкка китерүчегә) ышансалар да, алар арасында иләһ төшенчәсе аерылып тора. Мисал өчен, мөселманнар Аллаһның тиңдәшләре булуны яки "өчлек" нең бер өлеше булу фикерен кире кагалар һәм камиллекне бердәнбер Аллаһ белән генә бәйлиләр.

CONTENTS
































## Өченче ялгыш караш – **“Ислам терроризмны хуплый”.**

Массакүләм мәгълүмат чаралары, гадәттә, көрәшкән һәрбер мөселманны террорист буларак сурәтли, һәм аның гаделлек белән яки гаделсез сугышамы, башкаларны җәберли яки үзе җәберләнгәнме икәнлеген карамый.

Ислам сугыш алып бармаган, гаепсезләргә һөҗүм итүне, хәтта сугыш вакытында булса да - һичшиксез кабәхәт һәм тыелган эш икәнлеген ачыклый. Чынлыкта, сугыш вакытында мөселманнарга гаепсезләрне үтерү генә түгел, хәтта кирәксез рәвештә үсемлекләрне һәм хайваннарны юк итү дә рөхсәт ителми. Ләкин, терроризм белән оккупациягә легаль каршылыкны аерырга кирәк, чөнки алар ак белән кара аерылып торган кебек үк аерылалар.

Коръән гаепсез кешене үтерү җитдилеген ачык күрсәтә, һәм кеше гомеренең кыйммәтлегенә басым ясый.

***“Әгәр кем дә булса гаепсез бер кешене хаксыз яки җир йөзендә бозыклык таратудан башка сәбәпләр белән үтерсә, ул бөтен халыкны үтергән кебек булыр. Әгәр дә бер кешене үлемнән коткарса, бөтен халыкны коткарган кебек булыр.”***

***Коръән, 5:32***

## Дүртенче ялгыш караш - **"Ислам хатын-кызларны җәберли".**

Исламда ир-атлар һәм хатын-кызлар Аллаһ каршында тигез санала, кылган эшләре өчен әҗер-савап һәм җәзасын алу ягыннан барысы да тигезләр. Кешеләрне Аллаһ каршында аерып торган бердәнбер нәрсә - аларның диндарлык дәрәҗәсе.

***"Аллаһ каршында сезнең иң хөрмәтлеләрегез – Аллаһтан ныграк курыкканнарыгыз."***

***Коръән, 49:13***

Бу аять кеше дәрәҗәгә һәм чын хөрмәткә бай яки фәкыйрь, кара яки ак, ир яки хатын булу сәбәпле түгел, ә диндарлык һәм тугърылык аркасында ирешүенә дәлил булып тора.

***Аллаһ ике җенесне дә, аларның физиологик, психологик һәм акыл аермаларын исәпкә алып, һәрберсенә төрле вазыйфалар һәм җаваплылык билгеләп барлыкка китерде.***

Ислам хатын-кызларга мисал өчен, тигез хезмәт хакы алу, тормыш иптәшен сайлау, белем алу, аерылышу һәм мирас хокукы кебек зур хөрмәт һәм дәрәҗә бирә.

Кызганычка каршы, җәберләнгән һәм хокуклары бирелмәгән кайбер мөселман хатын-кызлары бар. Һәм бу Ислам гаебе түгел. Проблема шунда ки, кайбер илләрдә кешеләр Ислам белән бернинди бәйләнеше булмаган үзҗирле практикаларга һәм гореф-гадәтләргә иярәләр.

## Бишенче ялгыш караш - **"Коръән - тарих яки шигырь китабы гына".**

Коръән - Аллаһ Тәгаләнең Җәбраил фәрештә аша Мөхәммәд ﷺ пәйгамбәргә иңдерелгән иләһи сүзе. Ул хаклык белән батылны


CONTENTS




























аера, һәм кешелек бәхет-сәгадәттә яшәсен өчен туры юл, һидәят нигезләрен үз эченә ала. Коръән элекке пәйгамбәрләрнең һәм аларның кавемнәренең тәҗрибәләреннән без файда, гыйбрәт алсын өчен сабаклар китерә. Шулай ук Коръән Аллаһ хакында, үзебез турында һәм барлыкка килүебезнең максаты булган Аллаһның берүзенә генә гыйбадәт кылу турында хәбәр итә.

Аллаһ кешеләрне максатсыз рәвештә, адашып яшәсеннәр өчен өчен яралтмады. Берәүнең иманы - үзенең акылын, ихтыяр көчен һәм фикер йөртү сәләтен кулланып, Аллаһның җибәрелгән могҗизалары аша хаклыкны тануда сынала. Һәм шушы могҗизаларның иң бөеге - Коръән.

Коръәннең үзендә дә бик күп могҗизалар бар, шул сәбәпле без аның дөреслегендә шикләнмибез.

## Алтынчы ялгыш караш - **“Хиҗаб җәберләүче әйбер”.**

**Коръәннең нәрсәгә чакыруын ачыклау өчен иң яхшы ысул - аны үзең уку.**

Хиҗабның нәрсә икәнлеген аңлар өчен, шуны белергә кирәк - мөселман хатын-кызлары тәннәрен тыйнак кием белән капларга, һәм якын ир туганнарыннан башка, чит булган ирләргә гәүдәләрен күрсәтмәскә тиеш. Ләкин, хиҗаб тышкы күренешләр генә түгел, ул шулай ук күркәм сүз, тыйнаклык, күркәм әдәп-әхлак та.

Хиҗабның күп кенә файдалары булса да, мөселман хатын-кызларының хиҗаб киюләренең төп сәбәбе - бу Аллаһның кушкан әмере, һәм ул бәндәләре өчен нәрсә яхшырак икәнлеген белә.

Хиҗаб хатын-кызның тышкы матурлыгына түгел, ә эчке рухи матурлыгына басым ясап көч бирә. Бу хатын-кызларга тыйнаклыкны, оялчанлыкны саклап, җәмгыятьнең актив әгъзалары булырга ирек бирә.

Хиҗаб кысу, җәберләү яки басынкылык символы булып тормый. Киресенчә, ул кимсетүче карашлардан һәм гаделсез сүзләрдән саклый. Киләсе тапкыр мөселман хатын-кызын күргәндә, аның яшерелгән акылын һәм фикерен түгел, ә тышкы кыяфәтен каплаганын белегез.

## Җиденче ялгыш караш - **“Барлык мөселманнар да гарәпләр генә”.**

Дөньядагы мөселманнарның 20% -ы гына гарәпләр, димәк, мөселманнарның якынча 80% -ы гарәп булмаганнар. Мәсәлән, гарәп мөселманнарына караганда Һинд һәм Индонезия мөселманнарының саны күбрәк.

Ислам тәглиматларыннан, кеше үзенең расасы яки төсе аркасында бүтәннәрдән өстен була алмый, һәм ул расизмның төрле чагылышларына каршы тора. Ислам бөтен кешелек өчен универсаль максат белән килде - һәрбер кеше бердәнбер Хак Аллаһны танып һәм Аңа гына гыйбадәт кылып тынычлык һәм уңышка ирешә ала.

CONTENTS




## Сигезенче ялгыш караш - **“Җиһад – терроризм”.**

Җиһадның асылы - дин өчен Аллаһка яраклы рәвештә көрәшү һәм корбан итү. Лингвистик яктан ул көрәшү, сабырлык, түземлек дигәнне аңлата һәм барлык яхшы эшләрне, һәм хәерлелек юлында сарыф итүне үз эченә ала, шуңа да җиһад йөрәк, тел һәм тән белән нәфес-һавага, шайтанга һәм дошманнарга каршы көрәшү . Иң киң таралган күзаллау - җиһадның хәрби формасы, ул җәмгыятьнең иминлеген саклау, җәбер-золым таралмасын һәм гаделлекне тарату өчен рөхсәт ителә. Бу төрле шартларга карап саклану яки һөҗүм рәвешендә булырга мөмкин.

## Тугызынчы ялгыш караш – **“Мөселманнар Мөхәммәдкә яки ай иләһенә табыналар”.**

Тагын бер ялгыш караш - мөселманнар Мөхәммәд пәйгамбәргә (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) табыналар, бу бөтенләй хакыйкатькә каршы килә, һәм Пәйгамбәребезнең  әйткән сүзләре белән җиңел генә кире кагыла: “Насаралар Мәрьям улы Гайсәне (чиктән ашып) мактаган кебек, мине (чиктән ашып) мактамагыз. Мин (Аллаһның) бәндәсе генә; шуңа да миңа: Аллаһның бәндәсе һәм Аның Рәсүле дип әйтегез.” (Бохари, 3445).

***Ислам мөселманнарны Аллаһның барлык пәйгамбәрләрен һәм рәсүлләрен хөрмәт итәргә өйрәтә - ләкин аларны хөрмәт итү һәм ярату аларга табыну дигән сүз түгел.***

Ислам мөселманнарны Аллаһның барлык пәйгамбәрләрен һәм рәсүлләрен хөрмәт итәргә өйрәтә - ләкин аларны хөрмәт итү һәм ярату аларга табыну дигән сүз түгел.

Мөселманнар "ай иләһенә" табыналар дип уйлау, тагын бер бөтенләй дөрес булмаган фикер. Исламда айга, кояшка яки Аллаһтан башка берәр нәрсәгә табыну катгый тыелган:

“Кояшка яки айга сәҗдә кылмагыз, чыннан да Аңа гыйбадәт кылсагыз, аларны барлыкка китергән Аллаһка сәҗдә кылыгыз.” (Коръән, 41:37).

Ислам Алланың тулы камиллеген, бөеклеген һәм уникальлеген таный. Ул - иң гадел һәм шәфкатьле иләһ. Коръәннең күп кенә аятьләрендә әйтелгәнчә, Аңа гына гыйбадәт кылу - Исламда иң мөһим ышану.

## Унынчы ялгыш караш - **“Ислам мәҗбүри никахлауны рөхсәт итә”.**

Никахлау - дөнья тирәли һәрбер илдә урнашкан һәм таралган гореф-гадәтләргә карап үтәлә торган эшләргә керә. Мәҗбүри никахлау мөселманнар белән чикләнмәсә дә, ләкин моны яманлык теләп, Ислам белән бәйләделәр.

CONTENTS
































Исламда ирләр дә, хатын-кызлар да тормыш иптәшен сайларга яки кире кагарга хокуклы. Мөхәммәд пәйгамбәр (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) әйтте: “Моңа кадәр кияүдә булган хатын-кыз (ир сайлауда) вәлисенә (кияүгә бирүче ир туганы) караганда күбрәк хокуклы, ә гыйффәтле (кияүдә булмаган) кыз белән киңәшләшергә кирәк, һәм аның дәшмәве аның ризалыгын күрсәтә.” (Мөслим, 1421).

## Унберенче ялгыш караш – **“Ислам кешеләрне мөселман булырга мәҗбүр итә”.**

Исламның матур хәбәрен башкаларга җиткерү һәм уртаклашу мөселманнар бурычы булса да, беркем дә Исламны кабул итәргә мәҗбүр ителми. Исламны кабул итү өчен, кеше чын күңелдән һәм ирекле рәвештә Аллаһка ышанырга һәм аңа буйсынырга тиеш, шуңа күрә, беркем дә Исламны кабул итәргә мәҗбүр ителергә тиеш түгел.

Түбәндәгеләргә игътибар итегез:

- Индонезиядә мөселманнар саны иң зур, ләкин анда Исламны алып килү өчен бернинди сугыш та булмаган.
- Буыннар дәвамында Гарәбстан ярымутравында 14 миллионга якын гарәп копт насаралары яши.
- Ислам - дөньяда иң тиз тарала торган диннәрнең берсе.
- Золым белән көрәшү һәм гаделлекне тарату җиһад алып баруның төп сәбәпләре булса да, кешеләрне Ислам динен кабул итәргә мәҗбүр итү аларның берсе түгел.
- Мөселманнар Испаниядә якынча 800 ел хөкем иттеләр, ләкин беркайчан да кешеләрне Исламны кабул итәргә мәҗбүр итмәделәр.

> *Аллаһ әйтә: “Диндә көчләү юк. Туры юл адашудан ачык аерылды”.*
> **Коръән, 2: 256**

## Йомгаклау.

Ислам турында ышанычлы булмаган чыганаклардан өйрәнү - куркыныч, һәм аңлашылмаучанлыкка китерә. Кешелекнең дүрттән бер өлеше ышанган Ислам турында, дөрес чыганаклырга нигезләнмичә, тикшермичә, ялгыш карашларга һәм ялган мәгълүматкә алданып кабул итәргә ашыкма.

Ул - иминлек, шәфкатьлелек дине. Шуңа да кешелек өчен туры юл булган Ислам дине җентекләп һәм тирән уйлану белән өйрәнүгә лаеклы.

CONTENTS


- ИСЛАМГА КЕРЕШ
- МӨХӘММӘД ПӘЙГАМБӘР
- МӘРЬЯМ УЛЫ ГАЙСӘ: АЛЛАҺНЫҢ РАСУЛЕ.
- ИСЛАМДА ИЛӘҺ ТӨШЕНЧӘСЕ
- КОРЪӘН Кешелеккә соңгы вәхи.
- ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ НИНДИ?
- Ислам турында ялгыш карашлар.
- ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ.
- КОРЪӘННЕҢ ФӘННИ МОГҖИЗАЛАРЫ
- ҮЛЕМ ҺӘМ АХИРӘТ.


# ИСЛАМДА ХАТЫН-КЫЗ ХОКУКЛАРЫ.

TATARI (08/10) حقوق المرأة في الإسلام FREE COPY

*Мөхтәрәм.*

*Хөрмәтле.*

*Кадерле.*


Dar Al Ber Society
www.daralber.ae

الإمارات THE EMIRATES

Your Path To Peace..

مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام

تصريح رقم:
(2017/139)

دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري
Islamic Affairs & Charitable Activities Department

www.islamicic.com


CONTENTS

























# Кереш сүз.

Исламдагы хатын-кызлар буйсындырылган, кимсетелгән, җәберләнгән дип санала - ләкин алар чыннан да шулаймы? Миллионлаган мөселманнар җәберләнгәнме, әллә бу ялгыш карашлар масса-күләм мәгълүмат чаралары тарафыннан уйлап чыгарылганмы?

Ислам хатын-кызларга, Көнбатыш хатын-кызлары әле күптән түгел генә күрә башлаган хокукларны инде 14 гасыр элек бирде. 1930-нчы елларда Энни Бесант күзәтте: “ Христиан Англиясе соңгы егерме елда гына хатын-кызның милеккә хокукын таныды, ә Ислам бу хокукны гасырлар дәвамында таныган иде. Ислам хатын-кызларның җаны юк дип вәгазьли дип әйтү яла ягу булып тора.” (Мөхәммәднең тормышы һәм тәгълиматлары, 1932).

Ир-атлар һәм хатын-кызлар барысы да бер кешедән - Адәм пәйгамбәр нәселеннән. Ислам аларның икесенә карата да гаделлек һәм игелекле мөгамәләне генә кабул итә.

# Әҗер-савапта һәм җаваплылыкта бертигез булу.

Ир-атлар һәм хатын-кызлар Аллаһка бер төрле гыйбадәт кылалар, ягъни бер үк иләһкә (Аллаһка) гыйбадәт кылалар, бер үк гыйбадәтләр үтиләр, бер үк мөкатдәс китапка иярәләр һәм бер үк ышанулар тоталар.

Аллаһ (гарәп сүзе, мәгънәсе: барлык мәхлуклар өчен бердәнбер хак иләһ) барлык кешеләрне гадел һәм тигез хөкем итә. Аллаһ Коръәннең күп аятьләрендә ирләргә дә, хатын-кызларга да гаделлек белән мөгамәлә итүенә һәм әҗер-савап бирүенә басым ясый:

*“Аллаһ Тәгалә Коръән белән гамәл кылучы мөэмин ирләргә вә мөэминә хатыннарга асларыннан елгалар агучы җәннәтләр хәзерләде, алар анда мәңге калырлар, вә Гәден җәннәтләрендә яхшы урыннар хәзерләде.”*

**Коръән, 9:72**

*“Сезләрдән гамәл кылучының гамәлен Мин, әлбәттә, юкка чыгармыйм, ул гамәл кылучы кирәк – ир, кирәк – хатын булсын, гамәлдә барыгыз да бертигезсез.”*

**Коръән, 3: 195**

Бу аятьләр әҗер-савап бер кешенең җенесенә түгел, ә эшләренә бәйле икәнлеген күрсәтә. Кешенең нинди җенестә булуы, аның ничек әҗер-савап алу һәм хөкем ителүендә бернинди роль уйнамый.

CONTENTS































Әгәр дә без Исламны башка диннәр белән чагыштырсак, аның җенесләр арасында гаделлек күрсәтүен күрәбез. Мәсәлән, Ислам, тыелган агачтан ашаган өчен, Һава Адәмгә караганда гаеплерәк дигән фикерне кире кага. Ислам буенча, Адәм белән Һава икесе дә гөнаһ эшләделәр, икесе дә тәүбә иттеләр һәм Аллаһ аларның икесен дә кичерде.

## Белем алуда бертигез хокукта булу.

Ир-атлар да, хатын-кызлар да бер үк дәрәҗәдә белем эстәүгә чакырылалар. Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) әйтте: “Белем эстәү һәр мөселман өчен фарыз (мәҗбүри) булып тора”.

Шулай ук, хатын-кыз мөселман галимнәре Пәйгамбәр (с.г.в.) вакытында һәм аның тирәсендә булган. Кайберләре аның гаиләсеннән, икенчеләре аның сахәбәләре яки кызлары. Алар арасында күренеклесе Пәйгамбәрнең (с.г.в.) хатыны Гайшә булган, аның аша Ислам кануннарының дүрттән бер өлеше таралган.

Шулай ук, башка хатын-кызлар шәригатьнең бөек галимнәре булган, һәм аларның шәкертләре арасында танылган ир-ат галимнәре булган.

## Тормыш иптәшен сайлауда бертигез хокукта булу.

Ислам хатын-кызларга тормыш иптәшен сайлау һәм өйләнгән соң үз гаиләсенең фамилиясен саклап калу хокукын биреп хөрмәт итә. Шуңа да карамастан, күпләр ата-аналар кызларын кияүгә чыгарга мәҗбүр итәләр дигән фикердә. Бу кайбер җирлекләрдәге практика гына, һәм Исламда моның нигезе юк. Чынлыкта, бу тыелган.

Пәйгамбәр (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) вакытында аның янына бер хатын килеп әйтте: “Әтием, үзенең абруен күтәрү өчен, мине икетуган ир туганыма, мәҗбүри кияүгә бирде.” Пәйгамбәр кызның әтисен чакырды, аннары аның каршында кызга кияүгә чыгарга яки никахны туктатырга мөмкинлек бирде. Ул (хатын) җавап бирде: “Йә Рәсүлуллаһ, мин әтиемнең эшен кабул иттем, ләкин мин башка хатын-кызларга (алар никахка мәҗбүр ителмәячәкләрен) күрсәтергә теләдем.”

## Алар тигез, ләкин төрле.

Гомуми принцип буларак ирләр һәм хатын-кызлар тигез хокуклы булсалар да, аларга бирелгән конкрет хокуклар һәм бурычлар бертигез түгел. Ир-атларның да һәм хатын-кызларның да хокуклары һәм бурычлары бар.

CONTENTS
































Галимнәр, тышкы һәм эчке анатомик аермалардан кала, ир-атлар һәм хатын-кызлар миенең тел, мәгълүмат һәм эмоция эшкәртү процессында бик күп нечкә аермалар барлыгын беләләр, берничәсен генә искә төшереп:

Гарвард университеты социаль-биология белгече, Эдуард О. Вилсон әйтүенчә, хатын-кызлар ир-атларга караганда, тел осталыгы, кызганучанлык һәм иҗтимагый осталыклар белән аерылып тора, ә ир-атлар исә бәйсезлек, өстенлек һәм математик яктан осталык, һәм башка үзенчәлекләр ягыннан югарырак торалар.

Ике женескә дә бертөрле мөгамәлә иту һәм аларның аермаларын санга сукмау хикмәтсезлек булыр иде. Ислам, ир-атлар һәм хатын-кызлар бер-берсен тулыландыручы, ләкин төрле рольләргә ия булуларын өйрәтә, чөнки бу (рольләр) аларның табигатенә яхшырак туры килә.
Аллаһ әйтә:

*"Ә ир-ат хатын-кыз кебек түгел."*
(Корьән, 3:36)

*"Барлыкка Китеручe белмиме? Ул – Аллаһ һәрнәрсәне белеме илә чорнап алучы вә бик нечкә нәрсәләрдән дә хәбәрдар."*
Корьән, 67:14

# Гаилә бүлеге.

Аллаһ ир-атларны һәм хатын-кызларны һәрберсенә хас булган төрле рольләр, осталык һәм җаваплылык белән бар итте. Бу аермалар өстенлек яки түбәнлек дәлиле түгел, ә специализация. Исламда гаилә үзәк әһәмияткә ия. Ир-ат гаиләнең матди иминлеге өчен җаваплы, ә хатын-кыз гаиләнең физик, тәрбияви һәм эмоциональ иминлегенә өлеш кертә. Бу көндәшлеккә түгел, ә хезмәттәшлеккә этәрә. Үзара җаваплылыкны үтәп, көчле гаиләләр, димәк көчле җәмгыятьләр барлыкка килә.

Шулай ук, эмоциональ яктан, ирләр дә, хатын-кызлар да, бер-берсеннән башка бәхетле тормыш алып бара алмыйлар. Аллаһ моны матур итеп сурәтли:

*"Алар (хатыннарыгыз) сезнең өчен кием, ә сез алар өчен кием."*
Корьән, 2:187

Кием уңайлык, җылылык һәм куркынычсызлык бирә, өстәмә буларак кешене яхшы итеп күрсәтә. Исламда ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәт шулай билгеләнә.

CONTENTS
































# Ир белән хатын мөнәсәбәтләрендә мәхәббәт һәм шәфкать.

Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) шулай ук ир-атларга тормыш иптәшләренә иң яхшы мөгамәләдә булырга өндәде: “Сезнең иң хәерлеләрегез - хатыннарына яхшы булганнарыгыз”.

*“Аллаһның аятләреннән Аллаһның үзегездән сезнең өчен хатыннар юктан бар итүе, ул хатыннарыгызда тынычлык табып яшәвегез өчен, һәм сезнең арагызда мәхәббәт һәм мәрхәмәтлек булдырды, әлбәттә, Аллаһуның бу эшләрендә фикерли белгән кешеләр өчен гыйбрәт бардыр.”*

**Коръән, 30:21**

Гайшәдан (Пәйгамбәрнең хатыны) Пәйгамбәрнең үзен өйдә ничек тотуы турында сораштылар. Ул әйтте: “Ул өйдә сезнең кебек иде, ләкин ул иң йомшак һәм иң юмарт иде ... Ул өйнең гади эшләрендә хатыннарына ярдәм кулы сузарга әзер иде, ул үз киемен тегә һәм аяк киемен төзәтә иде.“ Гомумән, нинди генә эш булмасын, ул хатыннарына булыша иде.

# Аналарның һәм кызларның биек урыны.

Ана балага иң зур йогынты ясый, аеруча беренче елларда үзенең яратуы һәм кайгыртуы аркасында. Һичшиксез, җәмгыятьнең уңышы аниләргә бәйле. Шуңа күрә, Ислам аларның статусын хөрмәт итә һәм күтәрә.

Аллаh Коръәндә әйтә:

*“Без кешегә ата-анасына изгелек итәргә әмер иттек, аны анасы мәшәкать белән корсагында күтәрде вә мәшәкать белән тудырды.”*

**Коръән, 46:15**

Пәйгамбәрдән (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) бервакыт: "Әй, Рәсүлуллаһ, кешеләр арасында минем күркәм мөгамәлә итүгә кем лаеклырак?" - дип сорады. Ул: "Синең әниең", - диде. Бу кеше тагын ике тапкыр сорады: "Аннан соң кем?" һәм шул ук җавап бирелде. Дүртенче тапкыр да гына Пәйгамбәр "Аннан соң әтиең", - дип җавап бирде:.

Әҗер-савап аниләргә карата яхшы һәм игелекле мөнәсәбәттә булган өчен генә түгел, бәлкем Ислам, кызларны тәрбияләгән

CONTENTS






өчен, уллар тәрбияләү өчен бирелмәгән, махсус әҗер билгеләде.

Мөхәммәд пәйгамбәр (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) әйтте: "Кемгә Аллаһ ике кыз бала биреп һәм ул аларга карата игелекле булса, алар аның җәннәткә керүенә сәбәп булырлар."

# Йомгаклау

Исламга кадәр хатын-кызлар оят дип саналган, хатын-кыз балалар тере килеш күмелгән, фахишәлек киң таралган, аерылышу ир кулында гына булган, мирас малы көчле кешеләргә генә бирелгән, һәм җәберләү киң таралган, ә Ислам килеп, бу эшләрне бетерде. Хәзер дә, "алга киткән илләрдә" хатын-кызларга хөрмәт күрсәтелми, һәм берүк эш өчен берүк хезмәт хакы бирелми. Әмма дә ләкин Ислам, хатын-кызны кадерле дип саный, һәм ул хурланырга һәм түбәнсетелергә тиеш түгел. Кайбер Якын Көнчыгыш илләрендә яки мөселман гаиләләрендә хатын-кызларга карата начар мөгамәлә, Ислам дине аркасында түгел, ә кайбер мөселманнар ялгыш ияргән мәдәни факторлар аркасында. Әгәр дә Ислам җәберли торган дин булса иде, ни өчен бөтен дөнья хатын-кызлары ислам диненә керергә тели соң?

Барлык ир-атларны һәм хатын-кызларны барлыкка китерүче һәм Ризыкландыручы Раббыбыз һәм Раббыгыз сүзләре белән тәмамлыйбыз:

*“(Аллаһы Тәгаләнең бөтен хөкемнәренә буйсынып) Исламга кергән ирләр һәм Исламга кергән хатыннар, (ышанырга тиешле мәсьәләләрнең барысына да) иман китергән ирләр һәи иман китергән хатыннар, (әмерләрне тотып һәм тыюлардан тыелып) итагәть иткән ирләр һәм итагәть иткән хатыннар, (ниятләрдә, сүзләрдә һәм гамәлләрдә туры) ирләр һәм туры хатыннар, (тәкъдирләрендәге кыенлыкларга) сабыр иткән ирләр һәм (бөтен бәла-казаларга) сабыр иткән хатыннар, хошуглы ирләр һәм хошуг иясе хатыннар, (фарыз булган зәкятне һәм нәфел булган) садакалар бирүче ирләр һәм хатыннар, (фарыз һәм нәфел буларак) ураза тоткан ирләр һәм ураза тоткан хатыннар, җенес әгъзаларын (зинадан) саклаган ирләр һәм саклаган хатыннар, Аллаһны күп итеп зикер иткән ирләр һәм зикер иткән хатыннар, һичшиксез, Аллаһ болар өчен мәгъфирәт һәм зур әҗер әзерләде.”*

**Коръән, 33:35**

HOTLINE
+971 56 204 2045
islamicicdxb
islamicic.com info@islamicic.com +971 4 355 5223
DOWNLOAD TATARI FLYER
www.iicdxb.com/tatari

CONTENTS


Исламга керbegin

Мөхәммәд пәйгамбәр

Мәрьям улы Гайсә: Аллаһның расуле.

Исламда Илаһ төшенчәсе

Коръән Кешелеккә соңгы вахи.

Тормышның максаты нинди?

Ислам турында ялгыш карашлар.

Исламда хатын-кыз хокуклары.

Коръәннең фәнни могҗизалары


Үлем һәм ахирәт.


# КОРЪӘННЕҢ ФӘННИ МОГҖИЗАЛАРЫ


TATARI | (09/10) العلوم في الإسلام | FREE COPY


*"Аларга офыкларда һәм үз нәфесләрендә аятьләребезне күрсәтәчәкбез дә, алар беләчәкләр ки, ул (Коръән)- хак."*

*Коръән, 41:53*




Dar Al Ber Society
www.daralber.ae

الإمارات
THE EMIRATES

Your Path To Peace..

مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام

www.islamicic.com

تصريح رقم:
(2017/139)

دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري
Islamic Affairs & Charitable Activities Department


CONTENTS

























Ислам китабы, Коръән - Аллаһтан кешелеккә һәм пәйгамбәрләргә бирелгән иң соңгы вәхи китабы.

Коръән (1400 ел элек иңдерелгән), беренче чиратта, фән китабы булмаса да, анда күптән түгел генә технологияләр һәм фәнни белемнәр үсеше аркасында ачылган фәнни фактларга кагылышлы күрсәтмәләр бар.

Ислам уйланырга һәм фәнни тикшеренүләргә этәрә, чөнки барлыкка китерүнең табигатен аңлау, кешеләргә барлыкка китерүчеләрен зурларга, һәм Аның көчен һәм хикмәтен аңларга мөмкинлек бирә.

Коръән фән примитив булган вакытта иңдерелде, ул заманда телескоплар, микроскоплар яки бүгенге технологиягә якын булан нәрсәләр юк иде. Кешеләр кояшның җир тирәли әйләнүенә һәм күкнең җир почмакларында урнаштырылган баганаларга эленеп куелганына ышаналар иде. Шушындый күзаллаулар чорында, астрономия, биология, геология һәм зоология белән бәйле булган күп кенә фәнни фактлар турында ачык күрсәтмәләргә ия булган Коръән иңдерелде.

Коръәндә табылган күп фәнни фактларның кайберләре:

## 1 Тормышның килеп чыгышы.

Су барлык тереклекнең асылы итеп күрсәтелә. Барлык тереклек күзәнәкләрдән тора һәм хәзер без күзәнәкләрнең күбесенчә судан торганын беләбез.

Бу микроскоп уйлап табылганнан соң гына ачылды. Гарәбстан чүлләрендә яшәгән кемнеңдер, җирдәге бөтен тереклек судан килгән дип уйлавы күз алдына китерә алмаслык нәрсә.

> ***“Судан һәрбер нәрсәне тере иттек. Шулай да алар ышанмыйлармы?”***
> **Коръән, 21:30**

## 2 Кеше эмбрионының үсеше.

Аллаһ кеше эмбрионының үсеше этаплары турында сөйли:

> ***“Һичшиксез, Без кешене саф балчыктан бар иттек. Шуннан соң Без аны мәни (тамчы су) хәлендә ышанычлы урынга урнаштырдык. Шуннан соң ул мәнине “галәка” оешкан канга әйләндердек. Шуннан соң “галәка” оешкан канны "мудгаһ" чәйнәлгән ит хәленә әйләндердек... ”***
> **Коръән, 23: 12-14**

Гарәп телендә "галәка" сүзенең өч мәгънәсе бар: сөлек, эленгән әйбер һәм оешкан кан. "Мудгаһ" сүзе чәйнәлгән матдә дигәнне аңлата. Эмбриология галимнәре, бу терминнарның яралгы формалашуын сурәтләүдә кулланылуы төгәл булуын һәм үсеш процессын хәзерге фәнни аңлавыбызга туры килүен күзәтеләр.

CONTENTS































Кеше яралгыларының үсеш этапларын оештыру һәм классификацияләү турында егерменче гасырга кадәр аз беләләр иде, димәк, Коръәндә килгән кеше яралгысын сурәтләү җиденче гасырдагы фәнни белемнәргә нигезләнә алмый.

## 3 Галәмнең киңәюве.

Астрономия фәннәре әле дә примитив булган вакытта, Коръәндә түбәндәге аять инде:

***“Күкне Без зур көч белән төзедек һәм Без, әлбәттә, аны киңәйтәбез.”***

**Коръән, 51:47**

Югарыдагы аятьнең мәгънәләреннән берсе - Аллаһ галәмне (ягъни күкләр) киңәйтә. Башка мәгънәләр - Аллаһ галәмне саклый һәм аның өстеннән хакимлек итә - бу да дөрес.

Галәмнең киңәюве (мәсәлән, планеталар бер-берсеннән ераклашуы) узган гасырда ачылган. Физик Стивен Хокинг үзенең “Вакытның кыскача тарихы” китабында яза:

“Галәмнең киңәювен ачу егерменче гасырның интеллектуаль революцияләренең берсе иде.”

Коръән телескоп уйлап табылганчы да галәмнең киңәюе турында әйтә!

## 4 Тимернең җиргә төшерелүе.

Тимер җир өчен табигый түгел, чөнки ул бу планетага космостан килгән. Галимнәр ачыклаганча, миллиардларча ел элек җирне шартлаган ерак йолдызлардан тимер ташучы метеоритлар бәргән.

***“Шулай ук, тимер иңдердек. Ул тимердә каты сугыш куркынычы, шулай ук, файдасы да бардыр.”***

**Коръән, 57:25**

Аллаһ Тәгалә “иңдердек” сүзен куллана. Тимернең җиргә космостан метеорлар аша төшерелүе турында көчле фәнни фикер бар, бу җиденче гасырның примитив фәне белән билгеле булмаган әйбер.

## 5 Күкләрнең җир шарын саклавы.

Күкләр җир шарын һәм анда яшәүчеләрне кояшның үлем нурларыннан, шулай ук космосның каты салкыннарыннан саклауда мөһим роль уйный.

Аллаһ безгә түбәндәге аятьтә күкләргә карарга куша:

***“Без (Аллаһ) күкне саклана торган түбә иттек. Алар исә аның аятьләреннән йөз чөерәләр!”***

**Коръән, 21:32**

Коръән күкләрнең җир шарын саклавын Аллаһ Тәгаләнең көченең билгесе итеп күрсәтә, ләкин бу үзенчәлекләр егерменче гасырда үткәрелгән фәнни тикшеренүләр белән генә ачылды.

CONTENTS







## 6 Таулар.

Аллаh Тәгалә безнең игътибарыбызны тауларның мөһим характеристикасына юнәлтә:

> *“Без (Аллаh) җирне түшәк (кебек) ял итү урыны һәм тауларны кадак итеп ясамадыкмы?”*
> **Коръән, 78:6-7**

Коръән тауларның тирән тамырларын “кадак” сүзен кулланып төгәл сурәтли. Мисал өчен, Эверест тавы, җирдән якынча 9 км биеклектә, тамыры 125 километрдан тирәнрәк!

Тауның тирән баганага охшаган тамырлары булуы, егерменче гасыр башында тектоник плитәләр теориясе үсеш алганнан соң гына билгеле булды. Аллаh Тәгалә шулай ук Коръәндә таулар җир шарын ныгытуында зур роль уйнавын әйтә "... селкенмәсен өчен" (16:15), ә бу әле күптән түгел генә галимнәр тарафыннан аңлашыла башлады.




## 7 Кояш орбитасы.

1512-нче елда астроном Николай Коперник кояш үз системасының үзәгендә хәрәкәтсез тора һәм планеталар аның тирәсендә әйләнә дигән теориясен әйтте. Бу ышану астрономнар арасында егерменче гасырга кадәр киң таралган иде. Ә хәзер Кояшның хәрәкәтсез тормавы, ә безнең Саманча юлы галактикасы үзәге тирәли орбитадан хәрәкәт итүе яхшы билгеле.

Коръәндә бу искә алына:

> *"Ул (Аллаh) шундый Зат ки, көнне һәм төнне, Кояш һәм Айны барлыкка китерде, аларның һәрберсе үз юлында йөзә."*
> **Коръән, 21:33**

## 8 Океан эчендәге дулкыннар.

Гадәттә дулкыннар океанның өслегендә генә була дип уйлыйлар иде. Ләкин, океанографлар, кеше күзенә күренми торган һәм махсус җиһазлар ярдәмендә генә ачыклана торган эчке дулкыннар барлыгын ачыкладылар.

CONTENTS




Коръәндә бу искә алына:

***"...Тирән диңгездәге караңгылык кебек. Диңгезне дулкын каплап, ул дулкын өстендә дулкын, дулкын өстендә болыт, берсе өстендә берсе булган караңгылыклар..."***

**Коръән, 24:40**

Бу тасвирлау искиткеч, чөнки 1400 ел элек океаннар эчендәге эчке дулкыннарны ачу өчен махсус техника юк иде.

## 9 Ялган һәм хәрәкәт.

Мөхәммәд пәйгамбәр (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) заманында яшәгән рәхимсез җәберләүче кабилә башлыгы бар иде. Аллаһ Тәгалә аны кисәтер өчен бер аять иңдерде:

***"Юк! Әгәр дә ул тыелмаса, Без аны маңгай чәченнән тотачакбыз. Ялганчы, гөнаһлы булган маңгай чәченнән."***

**Коръән 96:15-16**

Аллаһ Тәгалә бу кешене ялганчы дип атамый, ләкин маңгаен (баш миенең алгы өлешен) «ялганчы» һәм «гөнаһлы» дип атый һәм туктарга кушып кисәтә. Күпсанлы тикшеренүләр ачыклаганча, миебезнең алгы (фронталь) өлеше ялган өчен дә, ирекле хәрәкәт өчен дә, һәм нәтиҗә буларак гөнаһ өчен дә җаваплы. Бу функцияләр егерменче гасырда үткәрелгән медицина күзәтү җиһазлары белән ачылды.


## 10 Кушылмый торган ике диңгез.

Диңгезләргә килгәндә, барлыкка китерүчебез Аллаһ Тәгалә әйтә:

***"Ике диңгезне ул бер-берсенә юлыга торган итеп җибәрде. Болар арасында киртә бар, алар бер-берсенә тиешмиләр."***

**Коръән, 55:19-20**

Суларның тыгызлыгы аермасы аркасында, җир өсте киеренкелеге дип аталган физик көч күрше диңгез суларының кушылуына комачаулый, әйтерсең лә, алар арасында нечкә дивар бар. Бу океанографлар тарафыннан күптән түгел генә ачылды.



CONTENTS






## Мөхәммәд аны яза алмый идеме?

Мөхәммәд пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) укый да, яза да белмәгәнлеге тарихта билгеле, һәм ул Коръәндәге фәнни нечкәлекләрне аңлата алырдай бер өлкәдә дә белем алмаган.

Кайберәүләр ул шул заманның гыйлемле кешеләреннән яки галимнәреннән күчереп алган дип әйтергә мөмкин. Әгәр дә ул нечкәлекләр күчереп алынган булса, без ул вакыттагы барлык дөрес булмаган фәнни фаразларның да күчерелүен күрер идек. Киресенчә, без Коръәндә нинди дә булса фәнни яки башка хаталар юклыгын күрәбез .

Кайбер кешеләр шулай ук яңа фәнни фактлар ачылгач Коръән үзгәртелде дип әйтергә мөмкин. Бу алай була алмый, чөнки Коръәннең төп телендә саклануы - тарихи документлаштырылган факт, һәм бу үзе бер могҗиза!

## Бу очраклы була аламы?

> **“Аларга офыкларда һәм үз нәфесләрендә аятьләребезне күрсәтәчәкбез дә, алар беләчәкләр ки, ул (Коръән) - хак.”**
> **Коръән, 41:53**

Бу брошюра перспектив фәнни могҗизаларга гына игътибар итсә дә, Коръәндә искә алынган могҗизаларның күп кенә исбатланган төрләре бар: тарихи могҗизалар, киләчәк турында әйтелеп, тормышка ашкан хәбәрләр, кеше әйтә алмаслык лингвистик һәм әдәби стильләр, һәм аларның кешеләргә тәэсир итүе. Бу могҗизаларның барысы да очраклы булырга мөмкин түгел, һәм алар Коръәннең, барлык фәнни кануннарның барлыкка китерүчесе булган, Аллаһтан икәнлеген ап-ачык итеп күрсәтәләр. Ул, бар пәйгамбәрләрне дә Аллаһка гына гыйбадәт кылу һәм Аның рәсүле тәгълиматларына ияру вазыйфасы белән җибәргән - бердәнбер Аллаһ.

Коръән - Аллаһның кешеләрне бөек максат белән яшәсеннәр өчен бар итүен күрсәтүче, туры юл (һидәят) китабы. Киресенчә, бу безгә тормышта мәгънәле һәм бөек максат барлыгын - Аллаһының камиллеген, бөеклеген һәм бердәнберлеген танырга һәм Аңа буйсынырга өйрәтә.

Аллаһ Тәгаләнең могҗизалары турында уйлану һәм алар белән танышу өчен, Ул биргән интеллектны һәм фикер йөртү сәләтләрен куллану – һәрбер кешенең үзенә бәйле. Һәм Коръән иң мөһим могҗиза. Уңышка ирешү өчен Коръәнне укыгыз, аның матурлыгын һәм хакыйкатен ачыгыз!

CONTENTS


Исламга керү
Мөхәммәд пәйгамбәр
Мәрьям улы Гайсә: Аллаһның расуле.
Исламда Илаһ төшенчәсе
Коръән Кешелеккә соңгы вәхи.
Тормышның максаты нинди?
Ислам турында ялгыш карашлар.
Исламда хатын-кыз хокуклары.
Коръәннең фәнни могҗизалары
Үлем һәм ахирәт.


# ҮЛЕМ һӘМ АХИРӘТ.

TATARI | (10/10) الموت والآخرة في الإسلام | FREE COPY


جمعية دار البر
Dar Al Ber Society
www.daralber.ae

الإمارات
THE EMIRATES

Your Path To Peace..

مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام

تصريح رقم:
(2017/139)

دائرة الشؤون الإسلامية والعمل الخيري
Islamic Affairs & Charitable Activities Department

www.islamicic.com


CONTENTS

























# ҮЛЕМ ЯКЫН.

Үлем - чынбарлык, аннан беркем дә кача алмый. Ул көн саен якынлаша, бәлки һәр сәгать, һәм һәр минут. 2007 елда бастырылган, Дөнья хакыйкатләре китабы мәгълүматлары буенча, секундына ике кеше диярлек үлә. Бу ел саен 57,9 миллион кеше! Һәрбер кеше яшенә, сәламәтлегенә, чыгышына, иҗтимагый торышына яки диндарлыгына карамастан, котылгысыз язмышка ирешәчәк.

> *"Кайда гына булсагыз да, үлем сезгә [һичшиксез] ирешәчәк, хәтта сез биек итеп салынган ныгытылган (сарай яки) кальгаларда булсагыз да."*
> Коръән, 4:78

Кайда үткән патшалар, миллиардерлар һәм көчлеләр? Кайчандыр матур, танылган, интеллектуаль элита кайда?

# ҮЛЕМ ЧЫНБАРЛЫГЫ.

Үлем афәт түгел, бу дөньядан икенчесенә күчү. Бу безне тормышның максаты, үлемнән соң нәрсә булачагы турында уйланырга этәрергә тиеш.

Аллаһ безгә Коръәндә безне Үзенә генә гыйбадәт кылу максатыннан барлыкка китергәне һәм бу тормышны шушы зур максатны кем үтәячәген сынау өчен биргәне турында хәбәр итте:

*"Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен генә бар иттем."*

Коръән, 51:56

Аллаһ безгә шулай ук үлем һәм тереклекнең максаты турында хәбәр итте:

*"Аллаһ сезнең кайсыгыз гамәлләренә күрә күркәмрәк булуын сынар өчен, үлемне һәм тереклекне яратты."*

Коръән, 67:2

Җеназа хезмәтен алдан түләп яки табут сайлап үлемгә әзерләнмиләр. Бәлкем тормыштагы хакыйкый максатны тормышка ашырып - Аллаһка гына гыйбадәт кылып, Аның кушканнарын үтәп һәм изге гамәлләр кылып әзерләнәләр. Исламда гыйбадәт төшенчәсе тормышның бар якларын да үз эченә ала һәм намаз уку белән генә чикләнми. Чынлыкта, Аллаһ разый булган һәрбер эш гыйбадәтнең бер төре булып санала, һәм кеше аның өчен бу дөньяда яки ахирәттә әҗерен алачак.

CONTENTS































# ҮЛЕМ МИЗГЕЛЕ.

*“һәрбер җан иясе иртәгәгә(Кыямәт көненә) нәрсә әзерләгәнен карасын.”*
(Коръән, 59:18).

Көн саен без үлем мисалларын күрәбез. Без тыныч кына үлүдә авырту да, авырлык да юк дип санйбыз. Ләкин бу алай түгел. Кеше үлгәндә, җан тәннән китә, һәм тәннең тышкы кыяфәте җан хәлен чагылдырмаска мөмкин. Җанның тынычлыгы яки тынычсызлыгы кешенең бу тормыштагы максатын никадәр яхшы үтәгәненең турыдан-туры нәтиҗәсе булачак, һәм үлемнең туры сәбәбе белән бәйләнеше бик аз.

Ике кешенең мисалын карап алыйк, алар беркайчан да булмаган урынга бер якка гына билет алган. Беренче кеше тел, культура һәм барасы урынга кагылышлы гадәтләр белән танышырга вакыт тапты. Ул дөрес валюта һәм прививкалар ала, һәм сәяхәт вакыты җиткәч, ул кӧтелмәгән хәлдә калмый. Ул иминлектә һәм канәгать, чөнки ул вакыт табып, әзерләнде.

Икенче кеше, киресенчә, әзерлегендә ваемсыз һәм бүгенге көн белән генә яшәп сәяхәт вакыты җиткәнче яши. Ул билгесез урынга курыккан һәм аптыраган хәлдә килә. Аның әзер булмавы аны коточкыч язмыш белән тәмамларга этәрә, чөнки үзе белән алып килгән әйберләрнең барысы да файдасыз иде.

Мондый игътибарсыз кешене сурәтләп, Аллаһ Коръәндә болай ди:

***“(Кяферләр ширек кылуларын дәвам итәчәкләр). Аларның берәрсенә үлем килгәч, [кылган гамәлләренә үкенеп] әйтер: «И, Раббым! Мине [тормышка] кире кайтар! Бәлки, мин калдырып киткәнемдә [намаз, ураза, хаҗ, зәкят кебек кылырга тиешле булган) изге гамәл кылырмын». Юк! [Аның бу үтенече берничек тә кабул ителмәячәк]. һичшиксез, ул [тормышка кайтарылу үтенече турында әйтелгән буш] бер сүз ки, аны ул [үзенә] әйтә.”***

Коръән, 23: 99-100

Шулай ук җәһәннәмгә кертелгән кешеләрнең җавапларын карагыз, аларны анда нәрсә керткәне турында сорау алганда:

***“[Җәһәннәм әһеле] әйтер: «Без намаз укучылар түгел идек. [Мөселманнар кебек] Мескеннәрне дә ашатмадык. [Аллаһның аятьләрен инкяр итүгә] Керешкәннәр белән без дә керешкән идек. Җәза көнен дә ялган дип саный идек. Хакыйкать [булган үлем] безгә килгәнче.”***

Коръән, 74:43-47

Барыбызның да үлем белән очрашырга билгеләнгән вакытыбыз бар, һәм без барыбыз да бу таныш булмаган урынга сәяхәт итәрбез. Үз-үзегездән сорагыз – сез моңа әзерләндегезме?

CONTENTS






























# ТОРМЫШНЫҢ МАКСАТЫ.

*“Без (Аллаһ) сезне уен-көлке буларак яралттык, һәм сез безгә (Аллаһка) кире кайтарылмассыз дип уйладыгызмы?”*

Коръән, 23:115

Тормыш - үлем белән тәмамланган сынау, ләкин ул кешенең бетүен билгеләми. Үлем килгәч, яхшылык эшләү мөмкинлеге туктый. Тәүбә итү өчен соң булыр һәм безнең язмыш, безнең хәзерге тормышыбызда эшләгән ышануларыбыз һәм эшләребез белән генә билгеләнәчәк. Кеше тормышы ике өлешкә бүленә: бу дөньяда кыска гына тормыш, һәм киләчәктә мәңгелек тормыш. Һәрбер акыл иясе, мәңгелек бәхет кыска гомерле ләззәтләргә караганда күпкә файдалырак дигән нәтиҗәгә киләчәк.

Аллаһ кешене барлыкка китерде һәм безгә сайлау иреге, яхшылык белән яманлыкны аеру өчен акыл биреп, үз эшләребез өчен җаваплы итте. Яхшылар әҗер-савап алган һәм яманнар җәзаланган ахирәт булмаса, бу Аллаһның камил гаделлегенә каршы килер иде.

Димәк, гаделлек булсын өчен, һәрбер кеше җавапка тартылачак Хисап көне булырга тиеш.

***"Без мөселманнарны гөнаһлылар кебек итәрбезме? Ни булды сезгә? Ничек (болай ялгыш) хөкем итәсез?"***

Коръән 68:35-36

# КЫЯМӘТ КӨНЕ.

*“Әйт: «Һичшиксез, сез кача торган үлем сезне каршы алачак. Шуннан соң сез бөтен яшереннәрне һәм күренгәннәрне Белгәнгә кайтарылачаксыз, Ул сезгә [дөньяда чакта] кылган нәрсәләрегезне хәбәр итәчәк.”*

Коръән, 62:8

Бу тормышта һәркемнең эшләре җентекләп язылган һәм сакланган, Аллаһ әйткәнчә:

***“[Колларның кылган гамәлләре язылган] Китап (кемнеңдер уң, кемнеңдер сул кулына, соңыннан мизанга] куелган. Гөнаһлыларның анда булганнардан курыкканнарын күрерсең. Алар: «Ни үкенеч безгә! Бу нинди китап! Кечкенә һәм зур булган бернәрсәне дә калдырмыйча, барысын да санаган», - дип әйтерләр. һәм бөтен кылганнарын каршыларында табарлар. Синең Раббың беркемгә дә золым итми.”***

Коръән, 18:49

Без бөтен гамәлләребезнең болай язылуының төгәллегенә таң калырбыз, һәм күптән онытылган гамәлләр искә төшерелер. Аллаһ әйтә:


CONTENTS


























*“Аллаһ аны [гамәлләрен) санады, алар исә аны оныттылар.”*

Корьән 58:6

Бу турыда тирән уйлану безне гөнаһ кылудан оялуга этәрергә тиеш, чөнки капма-каршысы булса, ул вакытта гөнаһлар безгә каршы язылачак һәм Кыямәт көнендә Аллаһ каршында күрсәтеләчәк.

Аллаһның үлгәннәрне терелтеп, аларны хөкем итүенең кодрәтендә шикләнүчеләр өчен, Аллаһ кяферләрнең сүзен китерә:

*“Үзенең [бер тамчы судан) яралтылганын онытып, (терелүне инкяр итү мәсьәләсендә] Безгә мисал [итеп онга әйләнгән сөякне] китерә һәм: «Бу череп беткән сөякләрне кем терелтәчәк?» - дип әйтә. Әйт(әй Мөхәммәд): «Аларны беренче мәртәбә Яралтучы терелтәчәк. Ул бит һәр яралтылган нәрсәне белүче.”*

Корьән 36:78-79

# Җәннәт һәм җәһәннәм.

Гыйбадәткә лаеклы бердәнбер зат - Аллаһ дип ышанган һәм изгелек кылган кешеләр җәннәт белән бүләкләнәчәкләр.

*“Һичшиксез, җәннәт әһелләре бүген [бер- берсенең хәлен белү, көйләр тыңлау, парларыннан зәвыклану һәм акылга да килә алмаган) күркәм шөгыльләр белән зәвыкланачаклар. Алар һәм хатыннары [кәе] күләгәләрдә [кыйммәтле пәрдәләр белән корылган сарайларның бүлмәләрендә булган) ятаклар өстендә кырын ятачаклар. Анда аларга җимеш һәм [җаннары] теләгән һәрнәрсәләре бар.”*

Корьән, 36:55-57

Мөхәммәд пәйгамбәр (Аллаһның аңа салаваты һәм сәламе булсын) риваять кылды: Аллаһ әйтте:

“Мин үземнең изге колларыма, беркайчан да күзләре күрмәгән, колаклары ишетмәгән, кеше йөрәге уйлый да алмаган, искиткеч әйберләр әзерләдем.”

Һәм, киресенчә, Аллаһның берлеген инкарь иткән кешеләргә җәһәннәм уты булачак һәм аларга әйтеләчәк:

“[Кяферләр җәһәннәм читенә китерелгәч, аларга: «Дөньяда чакта шайтанга ияргәнегез өчен] Сезгә вәгъдә ителгән җәһәннәм менә бу.

*[Дөньяда] Иман итмәгәнегез өчен бүген шунда янығыз.”*

Корьән, 36:63-64

Имансызлар өчен җәзаның иң катысы булачак:

*“Һичшиксез, җәһәннәм капкын. Чиктән ашканнар өчен кайту урыны. Алар анда чиксез заманнар буе калачаклар. Анда ни салкынча һава, ни [сусауны баса торган) эчемлек татымаячаклар. Бары [йөзләренә тидергән чакта тиреләрен өтеп алачак һәм эчкән чакларында эчәк- бавырларын өзгәләячәк*

CONTENTS





























*дәрәҗәдә кайнар су һәм [җәһәннәм әһеленең яраларыннан чыккан] эрен [эчәчәкләр]. [Дөньяда кылган начар гамәлләргә] Тиешле җәза булачак [бу газапларга дучар ителәчәкләр]. Чөнки алар [терелүгә ышанмаганнары өчен, кылган гамәлләре белән бәйле] хисапны көтмиләр иде. Безнең аятьләребезне дә тулысынча ялган дип саныйлар иде. Безнең аятьләребезне дә тулысынча ялган дип саныйлар иде. Без бит һәрнәрсәне санап һәм [Ләүхелмәхфүзгә язып куйдык. [җәһәннәмдә янган кяферләргә] «Алайса татыгыз [бу газапны]! Без сезгә газаптан башка бернәрсәне дә арттырмаячакбыз!» [дип әйтеләчәк].”*

Коръән 78:21-30

# ЙОМГАКЛАУ.

*“Әй, (терелүне инкяр иткән) кеше! [Сиңа сансыз нигъмәтләр биргән] Юмарт Раббыңа карата сине нәрсә алдый (шайтанның: «Теләгәнеңне эшлә, Раббың бик юмарт ул, шуңа күрә Ул беркемгә дә җәза бирмәс», — кебек сүзләренә алданасың]? Ул сине бар иткән, сине төзек [әгъзаларыңны кимчелексез) иткән һәм сине [килешсез булган нәрсәләрдән саклап үлчәүле иткән. [Моның кадәр җан ияләре арасында сине] Нинди шәкелдә [бар итәргә] теләгән [һәм якыннарыңнан кемгә охшатуны максат иткән] булса, сине шулай берләштергән. Юк! Сез шул җәза көнен (Кыямәт көнендә яхшылык өчен әҗер һәм явызлык өчен җәза) ялган дип саныйсыз.”*

Коръән, 82:6-9

Озакламый үлем чакыруына җавап бирербез, һәм безнең максатыбыз – Аллаһны ризалаштыру һәм ахирәт тормышына әзерләнү булырга тиеш. Дөреслектә, бу дөнья – үтеп китәчәк вакытлы бер форсат кына, шуңа күрә, хикмәт белән аны кулланыйк, үзебезнең һәм башкаларның хәлен төзәтик, шулай итеп без бу дөньяда да һәм ахирәттә дә уңышка ирешкән кешеләрдән булырбыз.

Үлем котылгысыз. Тормыштагы максатыбыз - Аллаһка гына гыйбадәт кылу, изгелек кылу һәм тыелган бар нәрсәдән саклану. Безнең киләчәк тормышыбыз хәзерге гамәлләребез нигезендә хәл ителәчәк, шуңа күрә, без җирдәге мөмкинчелекләребезне мәңгелек Җәннәткә урнашыр өчен куллана алабыз, яисә без аларны юкка чыгарып, Җәһәннәм җәзасына дучар булырбыз.

***“Һичшиксез, (иманлы һәм) тәкъва коллар нигъмәт эчендә. [Кяфер һәм] Гөнаһлылар ут эчендә.”***

Коръән, 82:13-14

مركز المعلومات الإسلامي
Islamic Information Center
للتعريف بالإسلام

Part of the

# ISLAMIC e-LIBRARY

Learn more about Islam with our informative and educational materials, translated to over 50+ languages

Quran Flyers Books

iicdxb.com/flyers

@islamicicdxb